ТАТАРСТАН хәбәрләре

Татарстан Республикасы халык депутатлары Советлары газетасы

25 февраль, 1993 ел.
ПӘНҖЕШӘМБЕ
№42(315)
Бәясе килешү буенча.

Фәкыйрьлектә яшәмәбез бит...

Кичә Татарстан Республикасы вице-премьеры Равил Моратов һәм Татарстан Президенты киңәшчесе Рафаэль Хәкимов журналистлар белән матбугат конференциясе уздырдылар. Ул республикабызның икътисадый проблемаларына багышланды.

Экономика хакында сүз чыкканда халыкны борчыган сораулар да читтә калмый, әлбәттә. Безнең тормыш-көнкүрешебез экономика белән турыдан-туры бәйләнгән бит.

Әйтик, шәһәр һәм поселокларда гөмбә кебек үсеп чыккан исәпсез киосакларны нишләтергә?

Равил Фатыйхович фикеренчә, әлегә киосклар бетәргә тиеш түгел. Алар моңа кадәр булган сәүдәгә альтернатив буларак калсын. Әлегә сәүдәне оештыручылар хөкүмәттән бина да, кредит та сорамыйлар бит. Димәк, мондый урам сәүдәгәрләренең эшчәнлеген хупларга кирәк. Ә инде анда тәртип урнаштыру мәсьәләсен, беренче чиратта, налог инспекцияләре һәм санэпидстанцияләр хәл итәргә тиеш.

Устав фонды, кереме кечкенә булган банкларны бетерергәме? Кайберәүләр шундый таләп куя. Ләкин республикада аларга караш башка булырга, банкларны саклап калырга һәм дә яңаларын булдыру хакында кайгыртырга кирәк. Бу өлкәдә эшлəрлек кадрлар — банкирлар үсеп чыгарга тиеш. Ә республикабызның Милли банкы ул матур вывеска кебек. Аны хәтта Россия банкының бер филиалы итеп карарга була. Аннан килеп, бердәм банк системасына кереп эшләүне дә хәл итәргә кирәк.

Әгәр урыннарда эшмәкәрлеккә бәйле инициативага киртә куела икән, бу зур ялгышлык булыр иде. Чөнки аны монда булмаса башка урында тормышка ашырачак ул. Республикабыз хөкүмәте моны яхшы аңлый. Татарстанны тыюлык зона итеп карап булмый. Предприятие яки сәүдә оешмасы җитештерелгән товарларны үзенә һәм республикага файдалы итеп сатарга тели икән, моңа нигә каршы төшәргә. Иң мөһиме халыкның акча керемен арттыру һәм адреслы яклау чараларын күрү зарур. Шунысы куанычлы, республикада бу юнәлештә нәтиҗәле эш алып барыла. Халыкның эш хакы даими үсәчәк. Ә балалар, әби-бабайлар, хәләл көче белән тормыш алып барырлык акча таба алмаучыларга адреслы социаль яклау карала. Бу 2 миллион 400 меңнән артык кеше, ягъни республика халкының өчтән ике өлеше чамасы. Моңа шәһәр һәм авыл җирләрендә яшәүчеләр керә. Әлбәттә, бу очракта кабат сорау туа. Азык-төлек һәм куллану товарлары бәяләре элекке хәлдә калырмы? Юк, билгеле. Ләкин республикабыз халкының кереме Россия Федерациясендәгеләрдән югарырак булырга тиеш. Моны Равил Фатыйхович аерым билгеләп үтте. Татарстан кешесе үзе алган акчага читтә йөргән чакта да киенерлек, тукланырлык булсын. Ә безгә товар алырга килүчеләргә артык иркенләп китәргә юл калмаска тиеш.

Мәгълүм булганча, Россиядә кайбер һөнәр ияләренең эш хаклары күп тапкырлар артты. Шуны күздә тотканда акча — әйбер алмашу процессында тигезсезлек килеп чыгар иде. Берәүләрнең начар тормышта, икенчеләрнең исә үтә мул яшәвенә китерер иде. Дөрес, Татарстан хөкүмәте халыкның керемнәрен тигезләү ягында түгел. Эшләгән кеше тиешенчә алсын да ул. Әмма түбәнгә тәгәрәүгә дә юл куелмасын. Ни өчен дигәндә, республикабыз халкының Россиядәгеләрдән ким эшләгәне юк. Аерым тармакларда күрсәткечләр бигрәк тә куанычлы. Әгәр дә бездә азык-төлек һәм башка куллану әйберләренең бәясе күтәрелмичә хәзерге дәрәҗәдә торса, киләчәктә халыкның бик авыр хәлдә калуы ихтимал. Моннан, адреслы социаль яклау чарасы күрү юлы белән генә чыгарга мөмкиндер. Әлбәттә, республикабыз хөкүмәте бәяләр үсү, эш хакын билгеләү, адреслы яклау мәсьәләләрен даими контрольдә тотачак. Димәк, хафаланырга урын юк.

Иң борчыганы — бүгенге көндә тышкы экономик элемтәләр. Бу Татарстан хөкүмәте эшчәнлегендә һәм халыкның тормышында да чагылыш таба. Әлегә кадәр Россия белән ике арада килешүләргә ирешмәү күп мәсьәләләрдә кулны тота. Әйтик, налог сәясәте, банклар эшчәнлеге, таможня мәсьәләсе һәм чит илләр белән элемтә урнаштыруда. Россияне читләтеп узып булмый. Иң элек Россия Федерациясе белән уртак фикергә килү, килешүгә ирешү зарур. Налог мәсьәләсен алып карыйк. Үзара уртак фикергә килми торып, республикабызда да бит бу өлкәдә мөстәкыйль адым ясап булмый. Ә республикабыз экономикасын ныгытуда, халык хуҗалыгын үстерүдә налогның үз мөмкинлекләре бар. Мисал өчен аерым предприятиеләргә, оешмаларга налог түләүдә вакытлыча ташлама ясарга мөмкин булыр иде. Бу вакыт эчендә алар производствоны киңәйтү, техник яктан баетуны һәм соңгы чиктә азык-төлек яки башка куллану товарларын эшләп чыгаруны җайга салыр иде. Кызганыч, әлегә бу мәсьәләләр эш процессын гына уза.

Татарстанның 1993 елга бюджетын карау да, тышкы экономик мәсьәләләрнең ачыкланып бетмәве сәбәпле, кичектерелгән иде. Республикабызның бюджетсыз эшләве дә безгә файдага дип әйтеп булмыйдыр. Равил Моратов сүзләре белән әйтсәк, моннан бары тик минуслар гына җыела.

Шуңа да Татарстан хөкүмәте республикалар, чит илләр белән үзара сөйләшүләрдә таяныр нокта табарга, экономик хезмәттәшлек урнаштырырга, бу юнәлештә нәтиҗәле эш алып барырга тырыша. Чит ил инвесторларына, эшмәкәрләренә киң юл ача. Андыйлар никадәр күп булса, республикабызның экономикасы шул кадәр тизрәк ныгыр дип уйларга кирәк.

Шунысын да әйтик, Россия Федерациясенең үзенең дә тышкы экономик сәясәт концепциясе эшләнмәгән. Мондый шартларда Татарстанның экономик проблемаларны хәл итүгә торган саен ныграк алынуы игътибарга лаек. Матбугат конференциясендә китерелгән күп кенә мисаллар моның ачык чагылышы. Ул бездә киләсе көнгә өмет уята, шул ук вакытта, эшчәнлек сферасындагы мөмкинлекләрнең барлыгын да күрсәтә.

Альберт САБИРОВ.

Т.З.Ахмаевны Татарстан Республикасының Актаныш районы администрациясе башлыгы итеп билгеләү турында

УКАЗ

Таһирҗан Зиннур улы АХМАЕВны 1993 елның 24 февраленнән Татарстан Республикасының Актаныш районы администрациясе башлыгы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.ШӘЙМИЕВ.

Казан, Кремль.
1993 ел, 24 февраль.

Район Советы сессиясе

24 февральдә халык депутатларының Актаныш район Советы сессиясе булды. Анда оештыру мәсьәләләре каралды.

Хуҗалык эшенә күчүе сәбәпле, Н.Нурлыев район Советы рәисе вазифасыннан азат ителде.

Район Советы Актаныш районы администрациясе башлыгы вазифасына Татарстан Республикасы Президенты тәкъдим иткән Таһирҗан Зиннур улы Ахмаев кандидатурасы белән килеште. Моңа кадәр Т.Ахмаев Америка-Австралия «Пионер» фирмасының тулы вәкаләтле вәкиле булып эшләгән иде.

Сессия эшендә Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе, Татарстан Республикасы халык депутаты Х.Низамов катнашты һәм чыгыш ясады.

Татарстан Республикасы Югары Советының матбугат үзәге.

Даими комиссияләрдә

Закон чыгару мәсьәләләре буенча комиссия утырышы булды. Аны Р.Хафизов алып барды. Утырышта дәүләт төзелеше, экономика һәм социаль-мәдәни төзелеш, суд реформасы мәсьәләләрен җайга салучы кайбер закон проектлары каралды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча «Дәүләт хезмәте турында», «Профессиональ союзлар турында» һәм «Татарстан Республикасында предприятиеләр һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Закон проектлары авторларга, эшләп бетерү өчен, кире кайтарылды.

«Медицина-социаль страхованиесе турында» Татарстан тән тикшергәннән соң, комиссия әгъзалары аның нигезендә медицина страхованиесе турында һәм социаль страхование турында ике мөстәкыйль Закон проекты эшләргә тәкъдим иттеләр.

Комиссия шулай ук «Мәгариф турында», «Татарстан Республикасында судьялар статусы турында», «Татарстан Республикасында суд төзелеше турында» Закон проектлары буенча эш группалары материалларын да карады.

Татарстан Югары Советының матбугат үзәге.

Татарстан Республикасы халык депутатлары игътибарына

Татарстан Республикасы Югары Советының уникенче чакырылыш ундүртенче сессиясе үзенең эшен 1993 елның 1 мартында иртәнге сәгать 10 да Татарстан Республикасы Югары Советының утырышлар залында дәвам итә (Ирек мәйданы, 1 йорт).

Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм кунакларны теркәү 28 февральдә көндезге 12 сәгатьтән башлап кичке 19 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумында үткәрелә.

Белешмәләр өчен телефоннар:
36-60-04
32-01-96

Алабуга моңнары

Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында «Алабуга моңнары» дип аталган район һәвәскәрләренең иҗат кичәсе булды. Алабуга төбәгендә туып-үсеп, хәзер башкалада гомер кичерүчеләр кичәне тамаша кылырга килгәннәр иде. Алар якташларының чыгышларын бик ошаттылар, һәвәскәрләрне алкышларга күмделәр, чәчәкләр бүләк иттеләр.

В.АБРОСИМОВ фотолары.

Үз хәбәрчебез Илдус Зариповтан, телефон аша

Линолеумга кытлык бетәр

Элек Чаллы төзүчеләре линолеумны чит илләрдән алалар иде. Хуҗалык элемтәләре өзелгәч, аңа зур кытлык килеп туды. Шуның аркасында йортлар айлар буе файдалануга тапшырылмыйча торды. Линолеум табылганчы төзүчеләр икенче төзелешләргә, я мәҗбүри ялга җибәрелде.

Шуларны истә тотып, ике ел элек «Камгэсэнергострой» берләшмәсе линолеум җитештерә торган «ПОЛИН» предприятиесе төзи башлаган иде. «Татстройматериалы», «Татсоцбанк», шәһәрне төзү идарәсе дә иптәшлек хокукында аның учредительләре булып торалар.

Хәзер ул предприятие продукциясен бирә башлады. Ниһаять, чит илләрдән һәм башка төбәкләрдән линолеум эзләп йөрисе калмады. Технологик җиһазлар сорап та предприятие бер кемгә мөрәҗәгать итмәде. Аларны ясау өчен дә үзендә «ПОЛИН—2» кече предприятиесе оештырылды. «ПОЛИН—1» тулы куәтенә югары сыйфатлы линолеум җитештерәчәк. Бу исә Чаллы ихтыяҗларын гына канәгатьләндереп калмаячак, ә тулаем Татарстанда линолеумга кытлык бетәчәк дигән сүз.

Безнең машина читтә җыела

Тольяттидагы автомобиль заводында төзелеп килә торган Алабуга заводында эшләп чыгару өчен «ЕЛАЗ—1125» маркалы аз литражлы машина үрнәкләре җыела башлады. Яңа автомобиль биш ишекле булачак. Егәрлеге — 56 ат көчле.

Мәңге халык күңелендә

Чаллы хакимият йортының концертлар залында Гаяз Исхакыйның туган көненә багышланган кичә булды. Аны региональ үзәкнең милли бүлеге хезмәткәрләре Роза Хәйдәрова һәм Фирдәвес Кәримова әзерләде. Әдәбият белгече доцент Әнвәр Шәрипов язучының тормыш юлы һәм иҗаты, ә яшь тарихчы Фәрит Шәкүров аның милли азатлык хәрәкәтендә тоткан урыны турында сөйләделәр.

Соңыннан Гаяз Исхакыйның тормышын һәм иҗатын яхшы белүчеләр конкурсына йомгак ясалды. Алдан аның сораулары «Нур» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында басылган иде. Аларга бик күп кешеләрдән җаваплар алынды. Чаллы һәм Тукай районыннан гына түгел, җавап хатлары язучының туган җире Чистай районының Яуширмә авылыннан, Актаныш, Зеленодол, Зәй, Мамадыш, Минзәлә, Чирмешән районнарыннан да килде.

Конкурс татар теле укытучылары һәм башка теләүчеләр арасында аерым үткәрелде. Алар арасында беренче урынны Тукай районының Теләче Тамак урта мәктәбеннән Мәдинә Хәлимова, икенче урынны 11 нче мәктәптән Сиринә Хисмәтуллина һәм Тукай районының Калмия мәктәбеннән Зөләйха Закирова, өченче урынны 46 нчы мәктәп укытучысы Гадилә Харрасова алды.

Ә конкурста ирекле катнашучылар арасында беренче урынга Чаллының техник лицей китапханәчесе Энҗе Мирсәетова чыкты. Икенче урынны ирле-хатынлы китапханәче Гөлфирә һәм КамАЗ эшчесе Мансур Сафиннар алды. Өченче урында — Алабуга педагогия институтының өченче курс студенты Ринат Якупов.

Халык Гаяз Исхакыйны онытмаган. Белә, хәтерли, хөрмәтли.

Китапханә китап сата

КАЗАН. Милли китапханә. Элек бирегә газета-журналлар карау, өйгә китаплар алып уку өчен киләләр иде. Хәзер бу белем йортыннан, анда өйрәнгәннәр һәм укыганнар өстенә, теләсәң шәхси китапллы булып та кайта аласың.

Яңа басылган әсәрләр белән беррәттән, бәяләр куелган китаплар да тезелеп киткән. Аларны «Китап йорты» кече предприятиесе һәм мәдәният фонды тәкъдим итә.

Китапларның, аеруча зур ихтыяҗ белән алына торган әсәрләрнең, алыпсатарлардан битәр, китап дөньясы белән турыдан элемтәдә торучы милли китапханә тарафыннан тәкъдим ителүе, әлбәттә, күңелле күренеш, җанга рухи ризык бирә торган вакыйга.

С.САБИРОВА.

Вазифасыннан азат ителде

Хуҗалык эшенә күчүе сәбәпле, Нургаян Гаян улы Нурлыев Татарстан Республикасының Актаныш районы администрациясе башлыгы вазифаларыннан азат ителде.

Һава торышы

Бүген, 25 февральдә, аз гына болытлы һава, явымсыз. Көньяк-көнчыгыштан секундына 3—8 метр тизлектә җил.

Казанда 9—11, Татарстанда 8—13 градус салкын.

26—27 февральдә аязучан болытлы һава. Төнлә 15—20 (урыны белән 26 градуска кадәр), көндез 7—12 градус салкын.

ҖИҺАН ТУЛЫ ХӘБӘР

Фермерларга — 25 миллиард сум

Россия крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясенең күптән түгел булып үткән съездында иң кискене — крестьян хуҗалыкларын язгы кыр эшләре башланганчы кредитлар белән тәэмин итү мәсьәләсе булды. Премьер-министр Виктор Черномырдин ул вакытта делегатларга чәчү башланганчы акча булыр дип вәгъдә биргән иде. Ул сүзендә торды. АККОР вице-президенты Юрий Линин хәбәр иткәнчә, хөкүмәт 200 мең фермер хуҗалыгын льготалы кредит белән тәэмин итү өчен шушы көннәрдә 25 миллиард сум акча биргән. Алар инде урыннарга җибәрелгән.

Яңартырга уйлыйлар

Татарстан Республикасы вице-премьеры Равил Моратов, февраль азагында Татарстан хөкүмәте белән Американың «Боинг» фирмасы арасында Казан аэропортын реконструкцияләү мәсьәләсе буенча килешү төзү ихтимал, дип белдергән. Ул 300 мең доллар торачак.

Ижау — Мәскәү арасында

1 июньнән бу маршрут буенча яңа поезд йөри башлаячак. Аның билетлары гадәттәгеләрдән 2,5 тапкыр кыйммәтрәк торачак. Составка, ресторан вагонынннан тыш, сөйләшүләр алып бару һәм килешүләр төзү өчен махсус вагон да тагыла.

Уҗым кышын да «үлми»

Виктор Черномырдин хөкүмәте Россия авыл хуҗалыгына дотация бирү турында тәгаен сүз алып бара һәм бу өлкәдә эшкә керешә. Безнең республикада моны 1992 елда эшләгәннәр иде. Татарстан хөкүмәтенең аграр секторлагы дөрес сәясәтен Россия хакимияте танырга мәҗбүр булды, шул җөмләдән галимнәр дә. Моны хәзер Мәскәү берәүдән дә яшерми һәм авыл хуҗалыгында Татарстан юлыннан атларга җыена.

Бу уңайдан Россия авыл хуҗалыгы академиясе әгъза-корреспонденты А.Постников «Земля и люди» атналыгында болай дип яза: **«Россиядә ашламалар куллану ике мәртәбә кимеде. Соңгы күп кенә елларда беренче тапкыр буларак, сөрү җирләрендә туклыклы матдәләр кимеде, хәзер элек кертелгән ашламаларның тәэсирен көтүгә ышаныч калмады. Бары тик Татарстан колхоз-совхозлары гына, ашламалар сатып алуга җирле бюджеттан акча бирелгәнлектән, былтыр тәэсирле матдәләр куллануны 1,5 тапкыр арттырдылар. Шуның нәтиҗәсендә бөртеклеләрдән рекордлы уңыш үстерелде.**

Минераль ашламаларны җитештерү һәм куллануны арттыруда кызыксынуны көчәйтүдән чыгып, Россия хөкүмәте бу максатка китә торган чыгымнарның 30 процентын федераль бюджеттан каплау һәм шулай ук авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүчеләргә льготалы кредит бирү турында карар чыгарды. Әгәр хөкүмәтнең бу ярдәме тулы күләмдә вакытында тормышка ашырылмаса, Россия 20—25 миллион тонна ашлык җыеп җиткерә алмаячак».

Безнең хөкүмәт сәясәтенең дөреслеген тану әйбәт. Соң булса да уң булсын, диләр бит әле. Былтыр ел башында Россия белгечләре, Татарстан 14 центнер чамасы гына уңыш алыр, дип юраганнар иде ләбаса.

Түбәндәге таблицага күз салыгыз. Иген игүчегә кышын безнең уҗым җирләрендә күпме дым булырга тиешлеген белеп тору кирәктер. Таблицада уҗым басуларында бер метр тирәнлектә былтыр кыш күпме күләмдә дым булуы турында мәгълүматлар һәм аның нормасы (миллиметрларда) китерелгән.

	1992 ел	Норма
Мәскәү өлкәсе	173	165
Түбән Новгород	195	156
Мордовия	174	131
Чувашия	153	142
Волгоград	113	67
Самара	101	93
Саратов	154	106
Ульяновск	153	103
Башкортстан	116	129
Оренбург	147	73
ТАТАРСТАН	149	135

Шушы нормадан чыгып, үз кырларыгыздагы дымны тикшереп карау комачауламас. Моны агрономнарга әйтүем. Уҗым кыш көне дә «үлми».

Мәгъсүм ГӘРӘЕВ.

Упкынга очудан саклау өчен...

укучы үз ысулын тәкъдим итә

Россия империясе чолганышында яшәгән Татарстан халкы кайсы юлны сайлап, нинди системада яши башларга тиеш? Бүген бу сорау безнең һәркайсыбызны уйландыра, дулкынландыра. Чөнки юнәлешне дөрес билгеләмичә, аз гына ялгыш борылыш ясасак та, кабат мәңге ычкына алмаслык коллык богавына элегүебез мөмкин. Кызганычка каршы, Россия лидерлары үз халкын да, империядән аерылган башка халыкларны да кризистан чыгарырга ашыкмыйлар. Киресенчә, алар икътисади һәм сәяси кризисларны бер-берсенә нык бәйләп, тирәнәйтеп, милләтара каршылыкларны тагы да үстереп, шул нигездә Россия жандармериясен яңадан ныгытып, таркалган империяне бер йозак астына берләштерү өчен, Иван Грозный, ПетрI даннарын үзләре исеменә мәңгеләштерергә янып йөриләр. Бүгенге көннең сәяси барометры шуны күрсәтә. Россия империясенең яңа туган жандармериясе үз эшен шушы хәлдә дәвам итсә, элеккеге СССР территориясендә яшәгән халыкларның берсе дә бервакытта да бүгенге хәлдән котыла алмаячак.

Ләкин кризистан чыгуның юллары бар. Аларның кайберсен хәтта Россия чолганышында яшәгән хәлдә дә тормышка ашырырга була.

Иң беренчесе — үзебезнең республикада тәртип урнаштырырга кирәк. Моның өчен Конституция нигезендә барлык хокук һәм тәртип саклау органнарының Татарстан юрисдикциясендә булуы зарур. Алардагы хезмәткәрләр санын арттырмыйча һәм сыйфатны күтәрмичә, үзгәрешкә өметләнеп булмый. Бүгенге көндә шәһәрләрдә талыйлар, яндыралар, җимерәләр. Авылларда машина белән килеп мал-туарны төяп китәләр, авыл амбарларын, кибетләрне басалар. Аның кадәр тәртип сакчысы каян табарга дип тә аптырыйсы түгел. Солдатка каралыр яшькә җиткән егетләребезне Татарстан Эчке эшләр министрлыгы карамагында калдырасы гына. Бу очракта МВДның бүгенге структурасы үзгәрми. Яңа көчләрне республиканың аерым төбәкләренә, үзәкләренә, эре тимер юл станцияләре тирәсенә кирәкле техника белән җиһазландырылган пунктларга бүлгәләп урнаштырырга туры киләчәк. Аларда хезмәт итүче яшьләр, гаскәри частьләрдә нинди практик тәҗрибәләр үткәрелсә, монда да шуны ук ашырга тиешләр.

Икенче юл — мөстәкыйль Татарстан дәүләтенең үз икътисадын булдыру.

Бүленмәс Россиянең реформа нәтиҗәләренә бәя биреп торуда мәгънә юк. Чөнки Россия халык депутатларының YII съездында хакимият җитәкчеләре үз бәһаләренең күпме торганлыгын бөтен дөнья халкы алдында күрсәттеләр. Без Россиядә, власть башына кайсы гына лидер нинди система белән килсә дә, кризистан чыгу юлы юклыгын ачык күрдек. Мондый болгавырлыктан фәкать үз икътисадый сәясәтебез булганда гына күпмедер дәрәҗәдә котылырга була.

Мин, Татарстан «сум» зонасыннан чыкмаган килеш, гомум кризиска бирешмәү чарасы бар, дип саныйм һәм укучылар игътибарына шуны тәкъдим итәм.

Бу — кризистан чыгу акциясе булдыру. Моның нигезе итеп минималь хезмәт хакын, яки минималь пенсияне алырга кирәк, дип саныйм.

Әйтик, бүгенге көндә минималь хезмәт хакы 2250 сум икән, шуны 10 мәртәбәгә киметеп, республика халкы санына тапкырларга һәм шул суммага акцияләр бастырырга кирәк. Татарстандагы бөтен төп продукция бәяләре шушы һәр кешегә тигән 225 сумнан чыгып бәяләнергә тиеш.

Мәсәлән, Татарстанда бүгенге көндә ипи 16 сум икән, акция белән ул 1 сум 60 тиен, ит 150 сум икән, ул 15 сумга төшә. Акция белән алучылар аны шушы бәядән ала. Ә «сум»га алучылар өчен, күрше республикаларның кайсысында иң югары бәя куелган булса, шул бәя бездә дә билгеләнә. Әйтик, Чувашиядә ипи — 20, ит 180 сум, Мари-Эльда ипи — 24, ит 160 сум. Ул чагында Татарстанда ипи — 24, ит 180 сум булырга тиеш. Югары бәядәге «сум»нарга сатылган продуктлардан килгән керем акция белән сатыла торган продукт бәяләрен төшерү өчен тотылырга тиеш. Шул чакта продукция бәяләре никадәр тизлек белән төшсә, банктагы запас акция күләме шул хәтле тизлек белән үсә барачак. Бу процессның үтәлешен Президент һәм Югары Совет тарафыннан билгеләнгән контроль комиссиясе күзәтеп торалар, дип фараз итик. Чөнки ул акция тиешсез күләмдә коррупция кулына эләгеп, әйләнеш тәртибе бозылса һәм шулай халыкта продуктлар сатып алуда тоткарлык килеп чыкса, моны контроль органнар тиз арада тикшереп, халык депутатлары алдында җавап бирә алачаклар.

Минималь хезмәт хакыннан артыграк хезмәт хакы алучылар һәм минималь пенсиядән югарырак пенсия алучылар акцияләрдән калган сумманы «сум»нарда алалар. Акцияләр, һичшиксез, гаиләдәге балалар өчен дә бирелергә тиеш. Ул ананың һәм атаның хезмәт хакыннан чигерелә. Ә инде 2 яки 3 бала белән ялгыз яшәп, хезмәт хакын җиткерә алмаган аналарга яки бөтенләй тәрбиячесез калган балаларны акция белән тәэмин итүне социаль яклау органнары хәл итә.

Югарыда мин шәһәрдә акцияләрдән файдалану тәртибе турында яздым. Ә авыл хезмәткәрләре һәм пенсионерлар өчен бу ярамый. Чөнки анда акция чәй, шикәр, аракыдан башкага кирәк булмаска да мөмкин. Ләкин бу һич тә алар акциядән мәхрүм кала дигән сүз түгел. Һәммәбезгә дә билгеле, бүгенге көндә авыл өчен кирәкле техника бәясе коточкыч дәрәҗәгә менде. Ә авыл хуҗалыгы продуктларын сатып алу алай ук күтәрелмәде. Авыл җирендә акцияләр менә шул тигезсезлекне киметү өчен файдаланыла ала. Моның өчен авыл хуҗалыгы техникасы бездә акцияләр белән бәяләнергә тиеш. Иң башта мин, республика мөмкинлекләреннән чыгып, бу максатка 20-30 процент дотация билгеләнергә тиеш, дип саныйм. Мәсәлән, «Беларусь» тракторы 200000 сум торса, Татарстанда ул 200000 — (200000x0,3) = 140000 сум була. Акциягә күчергәч, 14000 сумга бәяләнә. Колхоз-совхозлар, үз хезмәткәрләренә тиешле акцияләрне берләштереп, үзләренә кирәкле техниканы әнә шул түбән бәягә сатып алачаклар. Түләү һәм куллануның мондый системасына күчү фермер хуҗалыкларының да артуына китерер иде. Чөнки ул чакта гаилә әгъзалары, яки нәсел-нисбәт берләшеп, үзләре алырга теләгән техникага җитәрлек сумманы-акцияне туплый алалар.

Татарстанның үз акцияләре системасын булдыру, «сум» зонасында көтелмәгән реформалар килеп чыкса, инфляция артса, акча реформасы ясалса да, аның халкын кризис упкынына очудан саклап кала алачак. Шул ук вакытта ул үз акчабызны булдыруда бер сынау — тәҗрибә чоры да булыр һәм безне Украинада купоннар белән ясалган уңышсыз тәҗрибәдән коткарып калыр.

Нәфыйкъ ГОМӘРОВ,
инженер.
Зеленодол шәһәре.

Мөнәсәбәт

Әйдәгез, үзебезчә сөйләшәбез...

Һәр милләтнең милләт буларак яшәешен чагылдыручы иң мөһим күрсәткеч — тел. Тел үлсә, милләт тә яши алмый, тел яшәсә, милләт тә яши. Шуңа күрә дә, шовинистик көчләр халыкларны руслаштыру максатында беренче чиратта аларның телләрен, диннәрен бетерүне, иманнарын какшатуны күз алдында тоттылар һәм моңа әлешчә ирештеләр дә. Аерым милләтләр тулысынча юкка чыктылар, ә күпләренең үсешенә гаять зур тоткарлык ясалды.

Шуңа да карамастан, безнең халкыбыз үзенең телен, динен һәм гореф-гадәтләрен саклап кала алды. Дөрес, «манкортлар» дип йөртелүче, милли горурлык хисләрен җуйган, гореф-гадәтләрен һәм телләрен оныткан, тарихта эзсез калырга дучар ителгән кызганыч кешеләр бүгенге катлаулы көннәрдә милләтнең язмышы хәл ителгәнен аңларга сәләтсез. Ләкин монда аларны гына гаепләү дә дөрес булмас иде. Чөнки алар — гасырлар дәвамында үткәрелгән шовинистик сәясәтнең зәгыйфь җимешләре. Шулай да бер нәрсәне танымыйча булмый, телебезнең хәле бик тә аяныч. Конституциядә татар һәм рус телләре дәүләт телләре дип игълан ителсә дә, асылда татар теленең хәле үзгәрешсез калды. Телләр турындагы закон да моңа әлегә сизелерлек үзгәреш кертә алмады. Чөнки ике тел дә тигез дәрәҗәдә дәүләт телләре булып китсен өчен, бу телләрнең моңа кадәр дә тигез дәрәҗәдә үсүләре алшарт. Ләкин, әйтеп үтелгәнчә, моңа кадәр шовинистик көчләр төрле сылтаулар табып, фәкать рус теленең генә үсешен тәэмин иттеләр. Башка милләт кешеләре телиселәр дә, телəмисәләр дә, рус телендә укырга, кино карарга мәҗбүр булдылар. Бер яктан караганда, кеше никадәр күбрәк телләр белсә, ул рухи яктан шулкадәр баерак санала. Ләкин инде әгәр дә кешенең алга таба үсешен мәҗбүри рәвештә чит тел өйрәнеп, ана телен оныту белән бәйлиләр һәм моның өчен бөтен шартларны да булдыралар икән, бу вакытта ул — бу кеше өчен, бигрәк тә аның милләте өчен, фаҗигагә әйләнә. Бүгенге көндә татар теле шушындый фаҗигале хәлгә килеп җиткән дә инде.

Белгәнебезчә, кешелек дөньясында юкка чыгып баручы үсемлекләрне дә Кызыл китапка теркиләр һәм аларның үсеше өчен ниндидер аерым шартлар тудыралар. Әгәр инде бүген телебез шушы дәрәҗәгә калган икән, ни өчен аны үстереп җибәрү өчен махсус шартлар тудырмаска соң? Минемчә, Татарстан хөкүмәте моңа акча түгүдән куркып тормаска тиеш.

Чөнки татар телен, мәсәлән, Тамбов өлкәсендә тиешле дәрәҗәдә үстерү өчен җирлек юк. Аны фәкать Татарстанда гына эшләргә мөмкин. Соңгы елларда күп кенә татар гимназияләре яки татар класслары ачылды. Ләкин алар үзләренә йөкләнгән вазифаларны тулысынча үтиләр дип әйтергә иртәрәк әле. Татар теленә булган караш тамырдан үзгәреп килсә дә, укучыларыбыз тәнәфес вакытларында бер-берсе белән һаман русча сөйләшәләр. Билгеле, моның объектив сәбәпләре дә бар: әйтик, татарча укыту әсбаплары булмау, милли кадрлар җитмәү һ.б. Ләкин бик күп нәрсә ата-аналарның һәм укытучыларның фидакарьлегенә бәйләнгән. Чөнки укучылар тирәсендә милли мохит юк.

Татарстанда бүген халыкның якынча 50 процентын татарлар тәшкил итә. Шуның якынча 10 проценты, кызганычка каршы, үз телен белмәсеннәр дә, ди. Әгәр шул 40 процент бүгеннән башлап барлык урыннарда да, шул исәптән парламентта, эш урыннарында, трамвайда, өйдә үз телләренә күчәләр икән, бу инде Татарстанда татар теле 40 процентка дәүләт теленә әверелде дигән сүз.

Ләкин, кызганычка каршы, милләттәшләребез үз телләрендә сөйләшергә ашкынып тормыйлар әле.

Моның сәбәпләре нәрсәдә соң?Төп сәбәпләрнең берсе, әйтеп үтелгәнчә, гасырлар буена алып барылган шовинистик сәясәтнең нәтиҗәсе буларак, милли аңның түбән булуында. Биш гасырга якын татар теле бөтенләй диярлек үсмәде, аның үсеше, киресенчә, ясалма рәвештә тоткарланып килде. Шуның өчен дә бүген фән һәм җитештерү өлкәләрендә татар теле ярдәмендә аралашу бик тә кыенлашты. Чөнки терминнар юк. Бу туган телнең кулланышын бик нык тарайта. Ә бит кайчандыр Россиянең үз илчеләре дә күп кенә чит дәүләтләр белән татар теле аша аралашканнар.

Тагын бер сәбәп — ул да булса, татар телендә укытучы югары уку йортлары булмауда. Шул кайчандыр барлык ата-аналарны да балаларын бары тик рус мәктәпләренә генә укырга биреп, татар мәктәпләрен бөтенләй бетерүгә китергән иде инде. Ләкин бу өлкәдә бүген дә, кайбер институтлардагы группаларны иске алмаганда, әлләни алга китеш күренми.

Шунысын да әйтмичә булмый, гасырлар буенча рус теленә генә мәдхия җырлау кайбер милләттәшләребездә үз теленә карата ялган мөнәсәбәт тә тудырды. Бу мәсьәләдә кирәк булса да, булмаса да гел итагатьлелек күрсәтергә тырышабыз. Әйтик, 10 татар сөйләшеп утырган җиргә бер генә рус килеп кушыла икән, без вата-җимерә аның теленә күчәбез. Кем дә булса, 10 русның, бер татар килеп кушылды дип, татарча сөйләшә башлавын күз алдына китерә аламы соң?

Иң бөек фикер — иң гади фикер дигәндәй, ана телен дәүләт теленә әйләндерүнең иң гади юлы шул: әйдәгез, барыбыз да үзебезчә сөйләшик. Трамвай-троллейбус йөртүчеләрнең күпчелеге татар егетләре һәм кызлары: тукталышларны ана телендә дә әйтегез — сезне һәммәсе аңларга тырышыр. Оешмаларда утыручылар да анда гозер белән килүчеләрне ана теле белән каршы алсалар — бу беркемгә дә сәер тоелмас.

Без бүген башка милләт кешеләрен татар телен өйрәнергә теләмәүдә гаеплибез. Татар теле тормышта кулланылмагач һәм аның алар өчен кирәге булмагач, ни өчен өйрәнсеннәр алар аны? Мине тагын бер нәрсә борчый: элекке елларда татар телендә газета-журналлар аз чыкканда, без аларның азлыгыннан зарлана идек. Күп булгач, төрле булгач — алучы юк. Аларда тарихыбызга, мәдәниятебезгә караган материалларны тагын күбрәк бирергә кирәк. Тормыш никадәр генә авыр булмасын, гаиләсенә бер-ике татарча матбугат алдыруны һәр татар үзенең намус эше дип санасын иде.

Телевизордан һәр кич балалар өчен «Әлли-бәлли-бәү» тапшыруын күрсәтәләр. Еш кына бу тапшыру телевизор аша әкият укуга, яхшы очракта бер әкияткә кагылышлы рәсемнәр күрсәтүгә кайтып кала. Әгәр алар белән беррәттән татар телендә кызыклы мультфильмнар күрсәтелсә, аларны татар балалары гына түгел, башка милләт балалары да бик кызыксынып карарлар иде. Шул ук вакытта бу тапшырулар татар телен өйрәнү буенча өстәмә дәрескә дә әйләнер.

Хөкүмәтебез дә татар теленә, ниһаять, йөзе белән борылыр дип ышанасы килә. Сессияләрдә сүз башында «хөрмәтле халык депутатлары» дип әйтеп кую белән генә татар телен үстереп булмый.

Фоат УРАЗАЕВ,
1 нче гимназия укытучысы,
запастагы майор.
Казан.

«Татхимчистка» производство берләшмәсе коллективы кием-салым һәм башка әйберләрне чистарту белән беррәттән, заказчыларны затлы мехлар белән дә куандыра. Моның өчен җәнлек, сарык тиреләрен кабул итү пунктына илтеп тапшырырга кирәк әлбәттә. Аларның берсе — Идел буе районындагы Турбинная урамында урнашкан. Эшкәртү чыгымнары бүгенге бәяләр белән чагыштырганда күпкә түбән. Ә сыйфаты, әлбәттә, иң элек чималыннан тора. Дөрес туналган һәм саклау таләпләре үтәлгән тире икән, аннан яхшы сыйфатлы ярымфабрикат чыгасына һич шик юк. Аннан инде үзеңә соңгы мода буенча пальто, тун тектерергә заказ бирергә генә кала. Боларның барысы мастер Валентина Семенова (арткы планда) һәм тире эшкәртүчеләр бригадиры Ольга Старова аша уза дисәк, ялгыш булмас. Ә Нина Ильина (уңда) кебек оста мехчылар сменага 60-70 тире эшкәртеп тапшыралар. Аларның матурлыгына, җиңеллегенә сокланып туймаслык.

Н.ҺАДИ фотосы.

Җиде кат үлчә...

Россиядә үткәрелә торган реформаларның иң зур һәм мөһим максаты — күп катламлы икътисад һәм көндәшле базар мохиты булдыру. Хосусыйлаштыру әлегә бик әкрен бара. 1992 елның октябрь башына 20 меңнән артык предприятие милек шәкелен (формасын) үзгәртте. Күп санлы плюс һәм минусларны күрү мөмкинлеге туды.

Башлап торып, шунысын күрсәтик: хосусыйлаштырылган предприятиеләрнең күпчелеге — 82 проценты муниципаль һәм 13 проценты республика милке иде. Нигездә алар һәммәсе дә ваклап сату челтәренә (10,8 мең), җәмәгать туклануына (3,2 мең) һәм көнкүреш хезмәтенә (6,8 мең) караган предприятиеләр. Хосусыйлаштыру темпы һәм күләме дә бик төрле. Мәскәүдә, мәсәлән, мондый предприятиеләр нисбәте Россиядәге уртача күрсәткечтән бик күпкә югары.

Анализ түбәндәге нәтиҗәләргә китерә: хосусыйлаштыру темпы төбәкнең икътисадый үсешенә һәм аның кайда булуына турыдан-туры бәйләнмәгән, монда төп нәрсә — җирле җитәкчелекнең сәяси карашы нинди икәнлегендә булырга тиеш.

Икенче нәтиҗә: хосусыйлаштыру әлегә кадәр кампания рәвешендә үткәрелә. Ул, беренчедән, хосусый милекчеләр сыйныфын тизрәк тудыруны һәм, икенчедән, җирле бюджетка өстәмә керем китерүне күздә тота. Хезмәт ияләренең киң катламын бу эшкә тарту идеясе сүздә генә кала, чынлыкта бу өлкәдә берни дә эшләнми. Инде әйтеп үтелгәнчә, хосусыйлаштыру ягыннан алда баручы Мәскәүдә, мәсәлән, 1992 елда хосусыйлаштыру программасына кертелгән объектларның 80 процenttан күбрәге йә конкурс буенча, йә аукционда сатылды, берничә предприятие генә акционерлаштырылды.

Кызганычка каршы, статистика берничә күрсәткечне генә: хосусыйлаштырылган объектлар санын, аларның тармактагы предприятиеләрнең нинди өлешен тәшкил итүен һәм бу эшнең күпме керем бирүен генә исәпкә ала. Ә күпме кеше эшсез калган, халык куллануы товарлары һәм кешеләргә күрсәтелгән хезмәт күләме, бәяләр һәм сыйфат ничек үзгәргән — мондый мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү белән статистика вакланмый. Социаль һәм икътисадый нәтиҗәләр нинди булачак — анысы да кызыксындырмый.

Хосусыйлаштыру киңәя барган саен регионнарның үзенчәлекле факторы һаман арта. Шунлыктан программалар һәм аларны тормышка ашыру механизмнарын эшләгәндә табигый шартларны һәм ресурсларны, транспорт-географик хәлләрне, социаль-икътисадый структураны, регион хуҗалыгының үсешен бик нык исәпкә алырга туры киләчәк.

Эш белән тәэмин итү мөмкинлеген, хуҗалыкның структур үзенчәлекләрен, халыкның социаль хәлен һәм яшен исәпкә алудан чыгып фараз иткәндә, Россия республикалары, край һәм өлкәләрен дүрт төркемгә берләштерергә мөмкин.

Беренче төркемгә хосусыйлаштыру темплары җитештерүнең аеруча нык кимүенә, ә эшсезлекнең бик нык артуына китерә торган регионнарны кертергә кирәк. Бу хәл халыкны социаль яклауны тәэмин итәргә тиешле җирле бюджетка чиктән тыш авырлык салачак. Мондый куркыныч янаган регионнар ретенә Иваново өлкәсе, Краснодар һәм Ставрополь крайлары, Дагстан, Кабарда-Балкар һәм Төньяк Осетия республикалары керә. Ләкин биредә табигый шартларның уңайлыгы, бик нык үскән транспорт челтәре булу, чит илләрнең капиталын кертүгә ирешү хосусыйлаштырылган тармакларны тиз арада теке күтәрергә мөмкинлек тудыра.

Икенче төркемгә, җитештерү һәм социаль өлкәләрдә кыенлыклар шактый булганлыктан, өстәмә тырышлык таләп итәчәк Мәскәү, Тамбов, Әстерхан, Ульяновск, Ростов, Оренбург, Чита, Камчатка өлкәләре, Приморье крае, Чечен, Ингуш һәм Тува республикалары керә. Биредә аеруча зур кыенлык бер-ике мәсьәләдә генә туадыр, шунлыктан кризисның кискенлеге биредә беренче төркемдәгедән бик күпкә кимрәк булачак.

Өченче төркемгә хосусыйлаштыру авыр промышленностька һәм хәрби җитештерүне конверсияләү программасына кагылачак, шуның аркасында тискәре нәтиҗәләр бик нык көчәячәк регионнар керә. Болар — Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре, Нижгар, Киров, Воронеж, Волгоград, Саратов, Самара, Курган, Свердловск, Чиләбе, Магадан өлкәләре, Хабаровск крае, Удмурт Республикасы буладыр. Бу төркемдә хосусыйлаштыру программасы аеруча җентекләп эшләнгән булырга тиеш. Аны тормышка ашырганда, төрле юнәлештәге вак һәм урта предприятиеләр санын бик нык арттыруны күздә тотарга кирәк, чөнки конверсияләнә торган тармактан кысып чыгарылачак эш көчләрен бары тик алар гына йотарга сәләтле.

Дүртенче төркемгә барлык калган өлкә, край һәм республикалар керә. Боларда алдан күрелгән яклау чаралары җитештерүнең бик нык кимүен, эшсезлекнең киң җәелүен булдырмый кала алачаклар.

Барлык төркемнәрдә дә халыкны социаль яклауны көчәйтү өчен федераль һәм республика объектларын хосусыйлаштырудан керә торган акчаларны җирле бюджетка күбрәк бирүне күздә тоту максатка ярашлы булачак.

Милли республикаларда, шулай ук аз санлы халыклар, яңадан торгызылган казаклар, якын илләрдән кайтучы качаклар яши торган районнарда хосусыйлаштыру өстәмә кыенлыклар китереп чыгара. Мондый урыннарда милекнең күмәк шәкелләрен күздә тоткан алымнарын куллану, традицион кәсеп һәм вак һөнәр предприятиеләрен җирле халыкка милек итеп алу өчен өстенлекле хокук бирү яхшырак булачак. Шулай ук репрессияләнгән халыклар, казаклар һәм качаклар яшәүче районнарда хосусыйлаштыруның җиңелрәк системасын эшләү дә бик әһәмиятле. Бу халык һөнәрен, тормышның бозылган рәвешен торгызырга, югалтуларны өлешчә булса да капларга мөмкинлек бирер иде.

Милли-региональ үзенчәлекләрне исәпкә алу аеруча зарур. Ул хосусыйлаштыруны тормышка ашыру өчен уңай шартлар тудырачак, тискәре нәтиҗәләрне юкка чыгарачак. Халык тикмәгә генә: җиде кат үлчә, бер кат кис, димәгән. Барысын да исәпләргә, үлчәргә кирәк — гаять зур эш башкарыла бит.

Борис ШТУЛЬБЕРГ,
икътисадый фәннәр докторы.
(«Ризаль-пресс»).

Вакыт — Вакыйга

Өстәлдә... лимон өлгерә

БАЛТАЧ. Районның «Хезмәт» газетасы редакциясендә бүлмә лимоннары үстерәләр. Редакция хезмәткәрләре иң беренче агач үсентеләрен Нижгар өлкәсенең Павлово шәһәре янындагы Богородск лимоннарыннан күп еллар элек почта аша соратып алганнар иде. Аларның тәҗрибәсе җитмәдеме, Павлово лимоннары Балтач һавасын үз итмәдеме — журналистларның өйләренә алып кайтып утырткан нәзберек үсемлекләр бер-ике елдан һәлак булдылар, редакциядәге бер агач кына үсеп китте һәм җимеш бирә башлады. Инде шактый карт булса да, ул һаман да үсә. Ә бу рәсемдәгесе шул карт агачның чыбыгын тамырлатып үстерелде. Быел җимешләре саргаеп килә инде. Эреле-ваклы унбер лимоны бар. Иң элек өзелгән ике лимон икешәр йөз грамм килде. Аны үлчәүгә салып караган кибетче кыз лимоннарның тәрәзә төбендә үсүенә ышанмады.

Р.ШӘРӘФИЕВ.
И.СӘМИГУЛЛИН фоторәсеме.

Хезмәт хакы өчен түгел

МИНЗӘЛӘ. Үз коллективының финанс хәлен яхшыртуга омтылу көтелмәгән идея-тәкъдимнәр тудыра. Шәһәрнең 4 нче балалар бакчасында «Бакча фонды» марафоны үткәргәннәр иде. Юк, үзләренең хезмәт хакын арттыру өчен түгел. Шушы юл белән җыелган акча бүлмәләрне бизәү, уенчыклар, башка кирәк-ярак алуга тотылды. Бакча көләп тора хәзер.

И.ШАҺИЕВ.

Төкле аягың белән

КАЗАН. Шәһәр администрациясе Федосеев урамында Әзәрбайҗан сәүдә вәкиллеге, Җиңү проспектында педагогия институты уку бинасы, «Иреклe чиркәү» христиан оешмасы өчен Журналистлар урамында гыйбадәт йорты һәм Җиңү проспектында Идел буе районы мөселман оешмасының мәчетен төзергә рөхсәт бирде. Администрация башлыгы К.Исхаковның махсус карарында республиканың сәүдә-промышленность палатасы өчен дә 1 мартка кадәр бина табып бирү турында әйтелә.

А.ЛАТЫЙПОВ.

Дуслык дуслык белән...

БАУЛЫ. Менә 40 елдан артык инде Башкортстанның «Туймазынефть» идарәсе Татарстанның Баулы һәм Ютазы районнары территориясеннән кара алтын суыра. Ә ул төбәктәге авыллар дуслардан «бүләккә» пычранган һава, җирләр, тозланган җир асты сулары алалар. Инде Әпсәләм, Татар Ташлысы, Иске Чүте һ.б. авыл халыклары кайчан [illegible]

Бусы мәсьәләнең бер ягы булса, икенчесе — нигә соң әле Татарстан үзенең җир асты байлыкларына үзе хуҗа түгел? Нигә әле күршеләрнең безнең җирдән теләсә ничек файдалануына, ә без аларның нефть өчен күпмедер акча бирүенә шөкер итеп ятабыз?!

Әлеге нефть чыгарыла торган төбәктә ел саен 6-7 скважина бораулана иде. Бу эшне дә баулыларның үз кулларына алыр мөмкинлекләре бар — Баулы бораулау эшләре идарәсе монда бер бораулаучылар бригадасын бик иркенләп тота ала, минемчә. Тагын шунысы да бар, өстәмә бригада оешкан очракта дистәләрчә эшчеләргә яңа эш урыны булыр иде.

Дуслык дуслык белән, әмма монда чик-чаманы белергә, үз байлыгыңа үзең хуҗа була белергә дә бик вакыт, югыйсә. Тиздән Татарстан Республикасы Югары Советы сессиясе үзенең эшен янә дәвам иттерер. Ә аның көн тәртибендә республиканың җир асты байлыклары турындагы мәсьәлә дә бар. Аны тикшергәндә халык депутатлары да, Югары Совет, Министрлар Кабинеты, «Татнефть» берләшмәсе җитәкчеләре дә үз сүзләрен кистереп әйтерләр, дип ышанасы килә.

Ф.СӘЛИМГӘРӘЕВ.

Өлкәннәр белән киңәшү зыянга булмас

ЮТАЗЫ. Күптән түгел район администрациясе урыннардагы ветераннар Советы рәисләре белән очрашу үткәрде. Администрация башлыгы Сәгадәт Төхбәтуллин районның икътисадый хәле, мөмкинлекләре, кыенлыклардан котылу өчен ниләр эшләүләре хакында бәйнә-бәйнә сөйләде, ветераннарны борчыган сорауларга җавап бирде. Ә инде, аларны, беренче чиратта, сәүдәдәге тәртипсезлекләр, башбаштаклыклар, бәяләрнең төрле җирдә төрлечә булуы борчый.

Хәл ителәсе проблемаларның берсе — район үзәге булган Урыссу поселогында эчәргә яраклы суның булмавы. Поселок, район администрациясе бу мәсьәләне хәл итү өстендә эшли, тиздән кешеләр суга кытлык кичермәсләр дип әйтергә өмет бар.

Янә бер мәсьәлә: район халкының Казан телевидениесе тапшыруларын карый алмавы. Моны хәл итү өчен районның көче генә җитеп бетмәс, республика хөкүмәтенең ярдәме дә кирәктер.

Ютазы авылында (ул район үзәге булган вакытта) базар шаулап-гөрләп тора, теләгән әйбереңне сатып алырга мөмкин иде. Ә хәзер ул базар юк инде. Район администрациясендә очрашу вакытында бу хакта да сүз булды. Ветераннар Ютазыда базарны торгызу мәсьәләсен күтәреп чыктылар, бу мәсьәлә дә уңай хәл ителер дигән өмет бар.

Санап кителгәннәр — ветераннар белән район администрациясе үткәргән очрашуда күтәрелгән мәсьәләләрнең берничәсе генә. Шушындый кыен вакытта аларны тиз генә хәл итү мөмкин булмаса да, картлар, өлкәннәр, тормыш тәҗрибәсе тупланганнар белән сөйләшү-киңәшү зыянга булмас.

Р.КАМАЕВА.

Төзүчеләр шатландыра

ӘЛКИ. «Салман» совхозында ит, сөт җитештерү яхшы бара икән, димәк, биредә кешеләр турында кайгыртучанлык күрелә, аларның яшәү шартлары яхшыртыла дигән сүз.

Узган ел унсигез гаилә совхоз төзеп биргән йортта яши башлады. Шунысын да әйтергә кирәк, терлекчеләр, игенчеләр белән беррәттән, авыл халкының галимлеген күтәрүдә, сәламәтлеген саклауда эшләүче укытучылар, табиблар да игътибар үзәгендә. Аларга да яңа йортлардан ачкыч тапшырылды. Әле күптән түгел Яңа Салман урта мәктәбендә остаханә төзеп файдалануга тапшырылды. Хәзер укучылар һөнәрчелек дәресләрен өр-яңа, уңайлы, җылы бинада үткәрәләр. Авыл төзүчеләре булачак игенчеләрне, терлекчеләрне һәм башка һөнәр осталарын әнә шулай шатландыра беләләр.

С.СӨЛӘЙМАН.

Хәким Сәлимҗановның тууына 90 ел

Сәхнәләрдә янды якты йолдыз булып

Хәким ага Сәлимҗанов,
Хәким ага...

Ул безнең телгә әнә шулай «абый» гына түгел, ага булып кереп калды.

Ә татар халкы үзенең сөекледәренә, хөрмәтлеләренә генә шулай ихтирам белән ага дип дәшә.

Хәким аганы сәхнәдә күрергә өлгермәсәк тә, безнең буын аны яхшы хәтерли. Радиодан аның тавышын, ачык дикцияле, төгәл һәм дөрес логикалы, камил сөйләмен ишетеп үстек. Без, аксакал артистларыбызга, шул җөмләдән, әлбәттә, Хәким агага, аллага табынган кебек табынып, сокланып, кызыгып та карый идек. Алар елмайса, кош тоткан кебек булдык, ә инде сүз кушса — үзебез канатлы кошка әйләнә идек... Якты, мөлаем, игътибарлы кеше иде Хәким ага. Ул күз алдында, күңелдә һаман бик җанлы, тере булып саклана. Күзләре, бер хикмәтле хәйлә бар кебек, елмаялар, колакны аның ягымлы, бераз карлыкканрак тавышы иркәли сыман. Аңа әле 90 гына булыр иде. Бүген ул сәхнәбезнең түрендә кояштай балкып чәчәкләргә күмелеп утырыр иде... Зирәк акыллы, яшьләрнекедәй искиткеч яхшы хәтерле, зиһенле, картаюны белмәс тынгысыз, дәртле җанлы Хәким ага 90 га кадәр генә яшәр төсле иде. Тукай әйтмешли, «чын карт кеби» өйдә, җылыда, тыныч кына кул кушырып утырса яшәр дә иде. Әмма ул, безнең тере тарихыбыз, җанлы энциклопедиябез үзенең белемнәрен, хатирәләрен, истәлекләрен халыкка, тамашачыларга, яшьләргә, театрны, тарихны өйрәнүчеләргә җиткерү юлында — изге юлда, чыгыш вакытында, иҗатта янып дөнья куйды.

Арабыздан Хәким ага киткәч, безне гасыр башы — Г.Кариев, М.Фәйзи, К.Тинчуриннар белән бәйләп тора торган, күзгә күренмәс бер рухи җеп өзелгән шикелле булды... Сагындыра ул... Бүген Г.Исхакый,Т.Рахманкулов кебек югалган җәүһәрләр табылган заманда, ул белгән мәгълүматлар безгә бик кыйммәт булыр иде.

Ләкин барыбер рәхмәтнең олысы аңа. Аның «Артист язмалары» дигән истәлекләр китабын ачсак та, сәнгать йолдызлары турындагы радио фондында саклаучы дистәләгән язмаларны, яисә ул куйган радиоспектакльләрне тыңласак та, Академия театры репертуарындагы Г.Ибраһимов әсәрләрен искә алсак, я карасак, («Тирән тамырлар» һәм «Татар хатынынилләр күрми» спектакльләре Хәким ага язган сәхнә варианты буенча куелган иде) без Хәким Сәлимҗанов иҗатының мәңгелек нәтиҗәсенә юлыгабыз. Яңадан Ф.Әмирхан, С.Сәйдәш, Һ.Такташ, Н.Таҗдарова һ.б.лар белән очрашабыз...Хәким ага үзенең озын гомерен тулысынча сәнгатькә, театрга, димәк, халыкка багышлады.

Аның шәҗәрә буенча чыгышы Әтнә яклары, Бәрәзкә авылыннан булса да, ул Оренбург ягында — Урал суы буендагы зур булмаган Орск шәһәрендә һөнәрче гаиләсендә туып үсә. Кечкенә генә бу шәһәр милли мәдәният үсешенә зур хезмәт куйган күренекле исемнәр белән бәйле. Ул — драматург Мирхәйдәр Фәйзинең, композитор Заһид Хәбибуллин, сәхнә осталары Галия Нигъмәтуллина, Бәдер Йосыпова, Рәфкать Фәйзинең туган ягы. Ә менә Орскида татар театрының атасы Г.Кариев һәм заманында тамашачыларның зур мәхәббәтен казанган талантлы артист М.Әпсәләмовның эшләп алулары инде бу вакытта җыр, музыка, әдәбият белән кызыксынып, үзешчән түгәрәкләргә йөри башлаган яшүсмер егет Хәкимнең киләчәктә халык артисты Хәким Сәлимҗанов булуына сәбәп була, алар белән очрашу, танышу аның дөньяга карашына гомерлек зур йогынты ясый, 20 нче елда ук М.Фәйзи, үз чорының алгы сафында якты фикерләр белән янучы, төрле кичәләр оештырып һәм анда үзе дә катнашып йөрүче бу актив егет турында бер язмасында болай ди: «Хәким Сәлимҗановның речесе һәм декламациясе миңа бик ошап, аның бер актер булып чыгачагына күңелем канәгатьләнде».

1923 елда, үзешчән «Таһир—Зөһрә» спектаклендә төп рольләрне уйнаучы Х.Сәлимҗановны һәм аның булачак тормыш иптәше Г.Нигъмәтуллинаны М.Әпсәләмов Казанга алып китә һәм яшьләр яңа гына ачылган театр техникумына кабул ителәләр. Махсус театр белеме алып беренче чыгарылышның яшь артистлары 1926 елда Татар академия театрында эшли башлыйлар. Хәким аганың үз сүзләре белән әйтсәк, «тарихка алтын хәрефләр белән язылырлык дәрәҗәгә ирешкән театрыма мин егет булып килеп кердем дә, чал чәч белән чыгып киттем».

Яшь артист беренче эшләре белән үк үзен талантлы итеп таныта. Аның тышкы кыяфәтенә, сәхнәдә дәртле, тормышчан яшәвенә, көчле, матур аһәңле тавышына режиссерлар да, тәнкыйтьчеләр дә, тамашачылар да тиз игътибар итәләр. Матбугатта театр турында чыккан язмаларда Сәлимҗановка карата Ф.Бурнаш «...иҗади вәгъдә һәм ышаныч уята», ди, ә Г.Кутуй «...бик тиз үсеп китте», дип артист өчен куануын белдерә. Х.Сәлимҗанов 50 ел буена сәхнәдә уйнаган рольләр арасында онытылмаслык булып тарихта калган дистәләрчә образлар бар. Зәйнетдин («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Габбас Галин («Томан арты», Ш.Камал), Яго («Отелло», Шекспир), Хлестаков («Ревизор», Гоголь), Айдар («Зифа», Н.Исәнбәт), Гыйльманов («Миңлекамал», М.Әмир), Павел Корчагин («Корыч ничек чыныкты», Н.Островский), Хәлил һәм Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), Мирзаһан («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Кудряш («Яшенле яңгыр»), Мурзавицкий («Бүреләр һәм сарыклар», А.Островский), Гаяз, Рамай («Чаткылар»), Тимеркәй («Бишбүләк»,/Т.Гыйззәт), Марат («Рәйхан»), Алчын («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт) һ.б.лар.

Хәким ага менә шундый төрле амплуадагы киң диапазонлы драма артисты буларак та татар театры үсешенә зур өлешен керткән. Әмма андагы зур тирән белем, таланты, оештыра белү көче һәм, әлбәттә, Ф.Әмирхан, С.Сәйдәшевләр шәкерте булу, дистә ел К.Тинчурин режиссерлыгы астында иҗат итү, аның әсәрләрендә уйнау, Такташ, Кутуй, Җәлил белән якын аралашу, дуслашу — Х.Сәлимҗановның режиссер-педагог, тәрҗемәче, тел остасы гына түгел, каләм остасы булып китүенә дә ярдәм итә.

30 елларда ук, театрның режиссеры буларак, ул Такташның сәхнә әсәрләре өстендә эшли. Өлмәт, Минзәлә театрларында «Кандыр буе», «Ул кайтты», «Мәхәббәт газабы» кебек күләмле спектакльләр куя. Ф.Әмирхан язган «Фәтхулла хәзрәт»нең прозадан сәхнәгә менүе дә Х.Сәлимҗанов каләме кодрәте белән була.

Танылган нәфис сүз остасы эстрада артисты булу өчен дә Хәким агага табигать бар мөмкинлекне бирә. Тырышлыгы өстенә хәтер, әдәби зәвык, килеш-килбәт, тавыш һәм сүз тәмен белү, аны җанландырып тамашачыга җиткерү. Моны дәлилләүче кинокадрлар булмаса да, радиода ул язган магнитофон тасмалары аша Г.Тукай, Һ.Такташ шигырьләрен тыңлап без моңа бүген дә ышанабыз. Радио белән Хәким аганы ярты гасырлык иҗат бәйли.

30 еллар башында ук инде, Камал I, М.Мутин белән бергәләп, беренчеләрдән булып радиоспектакльләр эшли башлыйлар. Радио фондында Хәким ага куйган дистәләрчә спектакль язмалары бар: «Газинур», «Галиябану», «Тукай», «Тукайның балачагы», «Козгыннар оясында», «Татар хатынынилләр күрми», «Тирән тамырлар», «Мылтыклы кеше», «Намус», «Ваня абый», «Анна Каренина» һ.б. Аның 20,30 елларга, Ватан сугышы чорында татар театрының иҗатына, Кариевка, Сәйдәшкә, М.Фәйзигә, Мутин, Такташ, Гыйззәт, Тинчуринга, Таҗдаровага багышланган хатирәләре нинди кыйммәтле тарихи чыганаклар.

Бу күпкырлы талант иясенең тагын бер бик мөһим ягын — аның яхшы кеше булуын әйтү кирәк. Әйе, бу бик кадерле сыйфат. Барлык сәхнәдәшләре, замандашлары хәтерендә Хәким ага гаять кешелекле, туры, хак сүзле, дустанә, ифрат юмарт җанлы, киң күңелле, ярдәмчел булып саклана. Данлы Академия театрын 30 елга якын талантлы җитәкләп, бердәм иҗат көченә туплаган күренекле режиссер М.Сәлимҗановны тәрбияләп үстергән ата буларак та без Хәким агага рәхмәтлебез.

Луара ШАКИРҖАН,
Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының музей мөдире.

Х. Сәлимҗанов образларда,

М.Әмир — «Миңлекамал». Гыльманов ролендә — Х.Сәлимҗанов.

К.Тинчурин — «Җилкәнсезләр». Зәйнетдин — Х.Сәлимҗанов.

гаиләдә һәм дуслары арасында

Х.Сәлимҗанов, Р.Ишморат, М.Сәлимҗанов.

Х.Сәлимҗанов һәм Г.Нигъмәтуллина алтын туйларында.

Сәхифәне журналист Илдар МИНГӘРӘЕВ әзерләде.

Хәким ага Сәлимҗановның татар милли сәнгатен, бигрәк тә аның театр һәм эстрада төрләрен үстерүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Дистәләрчә еллар татар театр сәхнәсендә уйнап җыйган гаять зур тәҗрибәсен ул яшьләр белән уртаклашып, аларга үрнәк булып яшәде. Казан театр училищесында актерлык осталыгыннан дәресләр биргәндә тупланган хәзинәсеннән оста файдалана иде ул. Аның шәкертләре арасыннан бүгенге көндә театр сәхнәсендә үз урыннарын тапкан, тамашачыларның ихтирамын казанып өлгергән Алсу Гайнуллина, Рузия Мотыйгуллина, Зөлфирә Зарипова, Дусил Касыймов, Нариман Гарифуллиннарны атап китәргә була. Хәким ага яшь буын артистларының уенын һәрдаим күзәтеп, аларга файдалы киңәшләр биреп торды. Театрлар өчен кадрлар әзерләү мәсьәләсе өчен дә борчыла иде ул. Хәтеремдә, Казан театр училищесында Марсель Сәлимҗанов җитәкләгән безнең актерлар курсы диплом эше итеп Н.Исәнбәтнең «Портфельле кияү» комедиясен күрсәткән иде. Спектакльдән соң Хәким ага безне үз янына җыеп: «Эшләр болай барганда татар театры әле үлми, яшәячәк», — дип безнең эштән үзенең канәгать булуын белдерде. Аның сүзләренең хаклыгын бүгенге көн раслап килә.

Артист, тәрҗемәче, педагог...

Укыту эше белән бергә Хәким Сәлимҗановның тагын бер, ифрат дәрәҗәдә файдалы хезмәтен әйтеп үтәргә кирәк. Ул «Нәфис сүз» дигән китап язып, татар профессиональ сәхнәсенә кадрлар хәзерләүдә сәхнә теле буенча бәяләп бетергесез, үз вакытында бердәнбер булган дәреслек авторы да иде. Ничәмә-ничә буын артистлар, үзешчән сәнгать коллективлары шушы дәреслектән файдаланып киләләр.

Моннан тыш Хәким ага беренчеләрдән булып татар тамашачыларын күп кенә Көнбатыш классиклары, рус әдәбияты классиклары Н.Островский, М.Горькийларның байтак әсәрләре белән таныштырган кеше. Борис Горбатовның «Бер төн» драмасы аның соңгы тәрҗемә әсәре иде. Гомумән алганда, Хәким ага татар теленә 20 дән артык әсәр тәрҗемә иткән. Шуңа күрә дә аның исеме хаклы рәвештә, татар театры тарихына АРТИСТ, ПЕДАГОГ, ТӘРҖЕМӘЧЕ буларак алтын хәрефләр белән язылырга тиеш.

И.КАМИЛ.

Вакыт — Вакыйга

Күршеләр тәкъдим итә

УФА. «Башнефть» берләшмәсе Татарстанның Баулы, Ютазы районнары территорияләрендә дә нефть чыгара. Моның белән «Туймазынефть» идарәсе шөгыльләнә. Сер түгел, моңа кадәр әлеге коллектив тарафыннан Татарстан өлешендәге җирләр, сулыклар пычратылды. Ике арада низаглар да, бәхәсләр дә булгалады. Мөгаен, хәзер моңа чик куелыр — Башкортстан Министрлар Советы Республикадагы экологик хәлне яхшырту буенча тәкъдимнәр кертү өчен комиссия оештырды. Аңа Министрлар Советы Рәисе урынбасары А.Харлов җитәкчелек итә. Әлеге комиссия нәтиҗәле эшләсә, республикабызның көньяк-көнчыгыш өлешендә экологик хәләт бераз яхшырыр, шәт.

З.ФАКИЛЕВ.

Бөек драматург истәлегенә

СИМФЕРОПОЛЬ. Әле күптән түгел танылган кырымтатар драматургы Гомер Ипчи юбилеена багышланган кичә булып үтте. Кичәне шагыйрь Шакир Сәлим ачып җибәрде. Ул Гомәр Ипчинең кырымтатар драматургиясенә нигез салучыларның берсе буларак иҗатының әһәмиятен билгеләп үтте, Исмәгыйль Гаспринский, Әсән Рефатов белән беррәттән торырлык, кырымтатар мәдәниятә үсешенә зур өлеш керткән шәхес икәнен әйтте. «Отелло» һәм «Гамлет»ның татарча куелуында да аның хезмәте зур. Әдипнең тормыш юлы хакында филология фәннәре кандидаты Исмәгыйль Кәримов сөйләде. Кыска гына вакыт эчендә Г.Ипчи 19 китап бастырып чыгарган, утызга якын пьеса, берничә роман һәм повестьлар язган, кырымтатар теленә 30 томлык әдәби әсәрләр тәрҗемә иткән. Әгәр дә аңа «халык дошманы» дип яла якмаган булсалар, аның иҗаты тагын да баерак булыр иде.

Соңыннан драматург Г.Ипчинең «Файше» пьесасы буенча куелган спектакльнең премьерасы һәм концерт күрсәтелде.

Г.КАДЫЙРОВ.

Бер класстан сигез медальче

НИЖГАР. Үткән ел Уразавыл мәктәбен 41 укучы тәмамлаган, шуларның сигезе укуларын алтын һәм көмеш медальләргә бетергәннәр. Бу хәл мәктәп тарихында беренче мәртәбә булган. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаучылардан Гөлнара Әхмәтбаева хәзер Мәскәү экологик-политологик университетында, Гүзәл Мөхәммәтҗанова Россия дәүләт медицина институтында, Ләйлә Мостафина Казан дәүләт университетының журналистика факультетында, Гүзәл Шәймарданова Нижгар промышленность һәм экономика техникумында укыйлар.

Әлбәттә, укучыларның шулай яхшы укуында мөгаллимнәрнең дә өлеше зур. Хәзер Уразавыл мәктәбендә 50 укытучы 550 балага сабак бирә. Унике укытучы «Халык мәгарифе отличнигы» исеменә лаек булганнар, ә математика укытучысы Е.Аляутдиновага «РСФСРның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелгән.

К.ФӘЙЗУЛЛИН.

Гарәпчә укырлар

ПЕНЗА. Шемышейка районының Усть-Уза авылы мәктәбендә һәм мәчетендә Төркиядән килгән мөгаллимнәр Ибраһим һәм Мостафа гарәп теле күнекмәләре һәм дин сабагы бирәләр. Шундый ук дәресләр Каменка районының Кобылкин авылында да башланыр дип көтелә. Шул нияттән авыл администрациясе һәм мәктәп директоры Уфадагы Диния нәзарәтенә хат юлладылар. Аларның теләге кабул булыр, сабак бирү өчен якын көннәрдә авылга мөгаллимнәр килер дип көтелә.

Н.ГАЛИЕВ.

Ислам альманахы чыгачак

САНКТ-ПЕТЕРБУРГ. Философия фәннәре докторы, профессор Александр Җамалиев редакциясендә 1993 елның март аеннан «Вакыт» исемле ислам альманахы чыга башлаячак. Ул 8 битле һәм башлап русча, аннан соң төрек, гарәп, инглиз телләрендә басылачак. Редакция советына философия, әдәбият һәм шәрык белгечләре, җәмгать эшмәкәрләре — тарихчы Даут Әминов; «Амаль» ислам хәйрия фонды президенты Шамил Агеев; Петербург мэрының баш киңәшчесе Ватанъяр Яхъя; философия фәннәре докторы, профессор Әнәс Хәлидов; Петербург университетының төрек филологиясе кафедрасы мөдире Виктор Гузев; режиссер Рәисә Алалыкина керә. Редакция шәрыкны өйрәнү институтында, Дворцовая набережная урамының 18 йортында урнашкан. Альманахны «Амаль» фонды оештырды.

Д.ӘМИНОВ.

Мәктәп юбилеена әзерләнә

ТУЙМАЗЫ. Шәһәрнең Мәҗит Гафури исемендәге 1 нче татар мәктәбе агымдагы елның 15 маенда үзенең 70 еллык юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнә. Бу мәктәп Башкортстанда Уфаның 25 нче мәктәбеннән кала (ул да Мәҗит Гафури исемен йөртә, элек бирегә күренекле «Галия» мәдрәсәсе булган) иң бай тарихлыларның берседер. Анда заманында бик күп танылган шәхесләр — галимнәр, генераллар, артистлар, дипломатлар белем алган.

Торгынлык елларында ул рус мәктәбенә әйләндерелгән, татар теле һәм әдәбиятын укыту тыелган иде. Өч ел элек бирегә яңадан татар класслары ачылды, татар балаларының «Әйлән-бәйлән» җыр һәм бию ансамбле оештырылды.

З.НИЗАМЕТДИНОВ.

ФИЗКУЛЬТСӘЛАМ!

ТУПЛЫ ХОККЕЙ. 24 февраль. Россия чемпионаты, 1 лига. «Ракета» (Казан) — «Волга» (Ульяновск) — 5 : 3

ЧАҢГЫДА УЗЫШУ. Швециянең Фалун каласында бара торган дөнья чемпионатында Әлмәттән халыкара классны спорт остасы Ольга Данилова да чыгыш ясый. 15 километрга классик алым белән шууда ул иң көчле сигез спортчы арасына керде.

ШАХМАТ. Испаниядәге Линарес каласында әле моңа кадәр күрелмәгән халыкара бәйге башланды. Г.Каспаров, А.Карпов, В.Иванчук, В.Ананд, Б.Гельфанд, В.Крамник, А.Широв, В.Салов, Я.Тимман, А.Белявский, Л.Любоевич белән бергә, анда безнең милләттәшләребез Гата Камский, Артур Юсупов, Евгений Бариев та катнаша.

ЙӨГЕРЕШ. Первоуральскида оештырылган «Европа-Азия-Европа» марафонында 42 километр 195 метрлы араны беренче булып Екатеринбургтан С.Могильников тәмамлады. Казан егете Сергей Ишмулкин җиңүче белән бер үк төрле нәтиҗә күрсәтеп (2 сәгать 23 минут 28 секунд), икенче урынны алды. Рафис Садриев — өченче, Олег Табаков — бишенче, Михаил Сумочкин алтынчы булдылар.

ТРАМПЛИННАН СИКЕРҮ. Лениногорск нефть техникумында укучы Юрий Юркин, шул ук шәһәрнең 5 нче мәктәп укучысы Азат Гыйлалов үсмерләр арасында Россия беренчелегенә Түбән Новгородта булып узган бәйгедә өченче-дүртенче урыннарны бүлештеләр. Шуның белән алар икесе дә үсмерләрнең дөнья беренчелегендә катнашырга әзер булуларын күрсәтте.

Аты барның даны бар

Җилдәй җилдерә юртаклар

Үткән якшәмбедә көн әллә ни салкын булмады. Төшкә таба юка болытлар арасыннан кояш та күренгәләп куйды. Кай ара һавада кар бөртекләре дә тирбәлде. Кыскасы, [illegible] көн әйбәт иде. Димәк, ипподромда юртаклар бәйгесе булачак.

Ат чабышлары көн уртасында башлана. Әле шул вакытны истә тотып, ипподромга алданрак юл тоттык. Анда килеп керүгә, ике көпчәкле (тәгәрмечләре велосипедныкына охшаган) арбачыкларга җигелгән тулпарлар күзгә ташланды. Алар тирәсендә ат йөртүчеләр кайнаша. Әнә, беренче булып, бәйге тотачак юртаклар, чабыш кырына чыгып, арбачык артыннан кар бураны уйната-уйната, старт алды күнегүләрен башлап та җибәрделәр. Менә нәкъ сәгать уникедә ярышларга җитәкчелек итүче — Казан ат заводының директор урынбасары Рәшит Хәбибуллин чаң какты. Бу — беренче чабышта катнашучыларны стартка китерергә, дигән «әмер» иде.

Зоотехник-селекционер Рәисә Хәмидуллина да, спорт судьясы Алексей Карпов та (ул дистә ел чамасы инде ипподромда атлар бәйгесе буенча шушы вазифаны башкара) — үз урыннарында.

Яңә чаң сугалар. Рәисә Солтановна берьюлы дүрт секундомерга баса.

— Бәйгедә «Прилив», «Вызов», «Памфлет» һәм «Ватерлоо» кушаматлы тулпарлар. [illegible] Халиков, Илдар Хәбибуллин, Җәүдәт Хәбибуллин һәм Светлана Азизова, — ди судья Алексей Трофимович микрофоннан.

Бу чабышта биш яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк атлар катнаша. Болары — күп бәйгеләр тоткан, узышларның нәрсә икәнен яхшы белгән чабышкылар. Алдан ук әйтик, һәр чабыш 1600 метрлы арада үтә. Шушы ара берничә «кисәк»кә бүленгән һәм кайсы атның ничә секундта шушы [illegible] үтүе [illegible] билгеләнеп барыла. [illegible] Казан ат заводында туган һәм тәрбияләнгән, өйрәтүләрне узган «Прилив» кушаматлы айгыр килде. Ул 1600 метр араны 2 минут 26,5 секундта үтте. Бу әйбәт күрсәткеч. Кышкы шартларда бигрәк тә. Димәк, 2 нче категорияле йөртүче Ф.Халиков, башкаларга караганда, чабышкысына оста идарә иткән.

Икенче чабыш 1990 елда туган атлар ярышы белән башланып китте. Бу бәйгедә 5 тулпар катнашты. Алардан беренче булып финишта 57 нче ат заводында туып-үскән «Иностранка» кушаматлы бия күренде. Казан ветеринария институтын тәмамлап, ике ел ипподромда ат йөртүче булып эшләүче Наталья Цыганова, тулпарының холкын һәм мөмкинлекләрен яхшы белгән хәлдә, атын көйле һәм җайлы куалады. Шуның нәтиҗәсе буларак, бу яшьтәге чабышкылар узышында беренчелекне яулады...«Иностранка» артыннан шул ук Спас районының Никольское авылында урнашкан 57 нче ат заводы айгыры «Дракон», аңардан соң Казан ат заводыннан «Росчерк», аның эзләренә бастырып Мөслим районының [illegible] айгыры «Зоркий» килделәр.

Өченче һәм дүртенче чабышларда да шул ук яшьтәге чаптарлар бәйге тотты. Казан ат заводыннан «Талька» (йөртүчесе Ф.Халиков), Бөгелмә районының «Сокольский» совхозыннан «Пилигрим» (йөртүчесе И.Блохин) җиңүче булдылар. Әлеге стандарт араны алар 2 минут 41,5 секундта һәм 2 минут 47,4 секундта үтеп, беренчелекне яуладылар.

Бишенче, алтынчы һәм җиденче бәйгеләрдә Мөслим районының «Урожай» колхозыннан [illegible] «Закат» (йөртүчесе Татьяна Бабаханова), шул ук хуҗалыктан «Зайка» [illegible], «Сокольский» совхозыннан «Гоборун» [illegible] җиңүчеләр булдылар.

Рәшит Хәбибуллин, чаңга катырак суга-суга, «команда» бирә, ә Рәисә Хәмидуллина, секундомерларда ат чабышлары нәтиҗәләрен төгәл билгеләп, күрсәткечләрне йөгерә торган тоным атларын сынау программасына яза торды. Судья Алексей Карпов бәйге нәтиҗәләрен тамашачыларга җиткерә барды.

Без бер катлы бина түбәсендә эшләнгән, атлар чабышын күзәтү өчен алгы ягы пыялаланган будкада утырабыз. Бирегә ипподромның чабыш кыры уч төбендәгедәй ачык күренә. Барысы да күз алдында. Аста, бина янына басып торган тамашачылар үзара нидер гәпләшәләр, кайберәүләре бәхәсләшә. Ә газетабыз фотохәбәрчесе Василий Абросимов, ялларын җилдә уйнатып, койрыкларын сузып чапкан тулпарларны суретка төшерер өчен, юлның әле бер, әле икенче читенә йөгерә.

Көндез сәгать бер тирәсендә көчле җил чыкты, ипподром кырында буран купты. Җил атларга каршы исеп, чапкан юртакларга комачаулады.

Соңгы сигезенче һәм тугызынчы чабышларда 1991 елда туган яшь юртаклар катнашты. Аларны махсус җиңел чаналарга җиккәннәр иде. Болары әле бәйге тотарга өйрәнеп кенә киләләр. Шуңа күрә юырту алымКайчак сикереп үк чаба башлыйлар, тизлекләре дә өлкән атларга караганда түбәнрәк. Алар арасыннан иң әйбәт чапканының — «Кумир» кушаматлы айгырның (йөртүчесе Н.Цыганова) күрсәткече 3 минут 35,6 секунд тәшкил итте. Билгеле, яшь атларның йөгерүләренә бәтерелеп искән каты җил дә кире йогынты ясады.

Чаптарларны сынау бәйгеләре тәмам. Узышлар кызыклы һәм оешкан төстә үтте. Соңыннан ат караучылар һәм йөртүчеләрнең берничәсе белән очрашып, алар белән әңгәмә дә корып җибәрдем.

Ипподром штатында ат йөртүче, ат караучы тугыз хатын-кыз бар. Аларның күпчелеге урта мәктәпне тәмамлаганда бирегә йөри башлаган, кем әйтмешли, аларга ат җене кагылган. Шундыйлардан Наталья Цыганова, Ирина Золотова, Лариса Ефремова, Гүзәл Миндубаева, Татьяна Бабаханова, Елена Калинина, Светлана Азизоваларны күрсәтәсе килә. Светлана Казан ветеринария институтында укый. Наталья һәм Татьяна шул ук институтны тәмамлап, ат йөртүче булып эшлиләр. Ә менә Светлана Платонова Казан техник университетында бик яхшы укый, ипподром штатында тормаса да, әйбәт ат йөртүчеләрдән санала.

— Мин атларны мәктәптә укыган чакта ук яраттым, — ди Наталья Цыганова. — Юртакларның холкын белмичә торып, бәйгеләрдә үзең көткән нәтиҗәләргә ирешеп булмый. Атның ышанычын яулау өчен аңа карата ягымлы да була белергә кирәк. Ул иркәләгәнне дә ярата.

Ветеран, оста ат йөртүче дәрәҗәсенә ирешкән, төрле өлкәгесендә җиңүләр китерешкән Җәүдәт ага Хәбибуллин да биредә эшләүче кызларны мактап телгә ала.

28 февральдә Казан ипподромында яңадан юртаклар бәйге тотачак. Бу юлы җиңүче чаптарларга, аларны йөртүчеләргә призлар тапшырылачак. Ә тамашачыларны кызыклы ярышлар көтә.

Касыйм ТӨХАУ.

Борис ЗИННӘТУЛЛИН

Ат мәзәге яки нигә җылыйсы килә

(Моңсу хикәя)

Барлы-юклы унлап калгач, атлар каравыл сугарга булдылар. Якты көндә тиктомалдан бөтенләй бетәргә димәгән, лабаса!Җыелыш җыйдылар. Барысы да тәртип кушканча эшләнде: авыру-сырхауны чигереп, кворум расладылар, президиум сайладылар, регламент билгеләделәр, беркетмә язарга иң укымышлы бияне утырттылар. Ягъни соңыннан тел-теш тидерерлек булмасын. Каравылын каравыл да, чыны ничек, ялган түгелме? Адәм рәтле кәгазең булмаса, бар, йөреп кара хәзерге заманда!. Төп сүз нәсел башлыгы карт айгырга бирелде.

— Кешеләр бик бозылды, бик азды, — диде ул. — Кем икәннәрен оныттылар. Бар белгәннәре — куышу да узышу, ызгышу да бүлешү. Ашарларына да бетеп бара лабаса! Инде безгә дигән солыга хәтле талашалар. Безнең, атларның диюем, бүгенге фаҗигале хәленә шул сәбәп.

— Дөрес, бик дөрес! — дип гөрләде җыелыш. — Ачлык игълан итикме әллә?

— Юк, юк! — диде карт айгыр. — Без болай да ач һәм ялангач. Минемчә, хәлебезне аңлатып Югары җыенга барырга, атларны саклау турында кичекмәстән закон чыгаруны таләп итәргә кирәк. Закон чыгарылмыйча шуннан китмәскә! Менә шул нәрсә безнең каравыл булыр. Депутатлар йокымсырап утырсалар, ультиматум, ягъни кисәтү куябыз. Нindине? Мәсьәлә болай тора. Кешеләр безне, ат җегәрлеге, дип, двигательләргә, моторларга дыңгычлап тутырдылар. Маңка малай кулындагы мопедка хәтле өч-дүрт ат тыгып куелган. «КамАЗ»ларны, атом корабларын, космос ракеталарын әйтмим дә инде — аларда без йөзәрләп, меңәрләп, миллионлап. Әгәр без, ягъни бүгенге калдык-постык тере атлар, баш күтәрсәк, шул миллионнар кушылмас идеме? Ничек кенә әле! Ләкин без дөньякүләм эш ташлауга бара алмыйбыз. Чөнки без — атлар! Безнең бурычыбыз — тарту һәм тарту, тәрәккыйлеккә хезмәт итү. Безнең җилкәдәге кешеләр менә шуны кисәтү һәм куркытып алу закон эшләүне тизләтер, дип уйлыйм. Ягъни таләп һәм кисәтү бергә кушыла.

— Миңа сүз бирегез! — дип, яшь бия чәчрәп чыкты. — Карт айгырның бөтен сүзе дөрес. Атларның кадере бетте. Менә минем колыным туарга тора. Аны хәзердән үк Алабуга машинасына тыкмакчы булалар. Миннән, бездән сорамый-нитми. Юк, юк! Беркетмәгә языгыз: үз колыным үз янымда булсын. Арендага җир алып, солы-печәнне үзем үстерермен, ач итмәм. Законга да колыннарны яклау турында статья кертергә кирәк.

— Ә мин нишләргә тиеш? — дип, кешнәп җибәрде чапкын елкы. — Йөгәнләүче дә, иярләүче дә, җигүче дә юк. Булырлыгы да күренми. Мәктәпкә барыр идем, анда да малайлар уенда гел шухыр-мухыр, музыка, видео. Пошилар арасына китсәң генә инде. Аларга игътибар зуррак. Кызыл кенәгәгә дә кертелделәр. «Ат» дигән исем күтәреп, мескен хәлдә йөргәнче, поши булуың хәерлерәк түгелме?

— Тукта әле, тукта! — диде карт айгыр. — Мәсьәләне кайнар баштан хәл итмиләр. Пошилар, имеш! Нәсел турында уйларга кирәк, закон турында. Син бит минем урынга каласы кеше, нәселне сакларга, дәвам иттерергә! Пошилар арасына качарга, имеш. Көлке, валлаһи...

Җыелыш, чыннан да, көлеп алды. Чапкын елкы кырыйга посты. Үпкәләде, билгеле. Ләкин, нишләмәк кирәк! Нәселгә каласың икән, телеңнән алда башың эшләргә тиеш...

— Димәк, — диде карт айгыр, — карар кабул итәбез. Атларны саклау һәм үрчетү хакында закон булдырырга. Шунсыз Югары җыеннан чыкмаска! Вәкаләтле делегация сайлыйбыз.

Сайладылар. Иртәгесен киттеләр. Урам тутырып баралар. Уңга-сулга карау юк. Машина кычкыртканны да ишетмиләр, светофорны да күрмиләр. Үзләренеке үзләрендә: закон кирәк. Ләкин Югары җыен кайда соң?

— Сорарга, белешергә... Халык белми булмас. Йә әле, шушы «Жигули» хуҗасыннан сорыйк.

— Әти, әти, болар бит — чын атлар, — дип, машинадан сөйкемле бер кызчык очып чыкмасынмы! — Әти, өйдә алып кайтыйк!

— Безнең урын юк, кызым? Алар бит гаражга да, балконга да сыймыйлар. Алар — атлары белән...

Ярар. Атлар икенче машинаны туктаттылар. Монысы «Волга» иде бугай. Машина хуҗасы: «Әнә шул юнәлештә барыгыз», — дип, уңга төртеп күрсәтте.Атлар шатланды. Юыртып киттеләр.Килеп җиттеләр.Капка өстенә зур итеп, «Ит комбинаты», дип язылган иде.

Рөстәм Әхмәтов:

Үс, халкым, үс!

Якын земляком, читателям газеты «Татарстан хәбәрләре», желаю в спорте и в жизни быть всегда на высоте!
Рустэм Ахметов
февраль 1993 года

Һәрберсе үк булмаса да, еллар безне ара-тирә дөньяның төрле якларында үсеп чыккан талантлы милләттәшләребез белән таныштырып тора. Алтмышынчы еллар ахырында да шундый бер хәл булып алды. Бердичев дигән каладан биеклеккә сикерүче Рөстәм атлы егет үсеп чыкты. Унҗиде яшендә ул спорт остасы булып җитеште, илдәге яшьләр бәйгесендә җиңү яулады, аннан соңгы елда Европа күләмендәге шундый ук ярышта бронза медаль алды. 1971 елда Советлар берлеге, СССР халыклары спартакиадасы, Европа чемпионнары булды. 1972 елда Мюнхенда үткән XX җәйге Олимпия уеннарында катнашты. Шуннан соң Казанга кайтып, Рөстәм Татарстан Журналистлар берлегендә газета-журнал хәбәрчеләре белән очрашкан иде. Һәм менә шул хәлләрдән соң егерме ел вакыт үткәч, «Татарстан хәбәрләре» редакциясендә сөйләшеп утырабыз.

— Нинди җилләр, нинди юллар белән?

— Безнең юллар һаман да шул бер инде — әлеккечә итеп әйтсәк «әбиләргә», хәзергечә әйтсәк, «апаларга» кайту.

— Әбиләр, апалар дигәнне ничек аңларга?

— Әти белән әни җәйләрен апам Ираида белән мине үзләренең туган яклары Буага кайтарып куя торганнар иде. Ялыбызның яртысын район үзәгендә, ә икенче өлешен Исәк авылында яшәүче әбиләребездә уздыра торган идек. Әбиләр хәзер юк инде, алар урынына әниемнең сеңелләре Рауза апа белән Сания апа калдылар. Үткәндә-сүткәндә мин шулар янына тукталып, хәлләрен белешеп чыгам.

— Әти-әниеңнәр үзләре исәннәрме соң әле?

— Рәхмәт. Исән-саулар. Һаман да Бердичевта яшиләр. Картайдылар инде, берсенә — 80, икенчесенә 63 яшь бит. Әнием инде күрми диярлек. Апам да алар янында тора, балалар бакчасында музыка дәресләре алып бара. Үзем Житомирда яшим.

— Сезнең белән тегә елда Казанда очрашканнан соң байтак гомер узды. Шул еллар эчендә тормышыгызда нинди үзгәрешләр булды? Сез хәзер нәрсә белән мәшгуль?

— Мин 1975 елга кадәр СССР җыелма командасына кердем, күнегүләр ясадым — ил данын яклап, ярышларда катнаштым. Бер үк вакытта, читтән торып укып, Киевтагы физкультура институтын тәмамладым. Аннан фәнгә кереп киттем. Өч ел Мәскәүдәге Бөтенсоюз физик культура фәнни-тикшеренү институтында аспирантурада укыдым. 1980 елда диссертация яклап, педагогия фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алдым. Шуннан бирле Житомирдагы Иван Франко исемендәге дәүләт педагогия институтының физик тәрбия факультетында эшлим, ун ел инде — доцент.

— Хәләл җефетегез кем, кайсы яклардан, гаиләгез зурмы?

— Хатыным Эльмира — үзебезнең милләт кешесе. Аның әнисе, ягъни миңа әби тиешле кеше — Казаннан. Танышуыбыз Кыргызстанда булды. Ул анда медицина институтын тәмамлаган — шикәр авырулары буенча белгеч. Ике улыбыз үсә. Олысы Ильяс — ун яшьтә, кечесе Илдар — дүрттә.

— Мин яшьлеген спортка багышлаган байтак кешене беләм. Алардан зур спорттан киткәч, тормышта урыннарын таба алмыйча интегүчеләр дә шактый булды. Ә сез ничегрәк?

— Гаиләдә һәм мәктәптә миңа төпле белем бирделәр. Сигезенчегә кадәр гел бишлегә генә укыдым. Бу миңа тормышыма ныклы нигез салырга ярдәм итте. Шулай булгач, спорттан китү баштарак үзен сиздерсә дә (ни дисәң дә, даным, байлыгым бар, бөтен кеше белә, ихтирам итә иде, ә бер мәлне йөз сумлык эшкә күчеп утыр әле, сизәрсең...), мин югалып калмадым.

— Соңгы мәртәбә нинди ярышларда катнаштыгыз? Спорт белән хушлашу ничегрәк булды?

— 1975 елда мин екренләп СССР җыелма командасыннан төшеп калсам да, күнегүләр ясаудан туктамадым. Ләкин янәшәмдә яшьләр үсеп, үкчәгә басып киләләр иде инде. Алар белән ярышу торган саен кыенлаша башлавын тойдым. Җитмәсә әле, күнегүләр вакытында, җайсыз егылып, аягымны сындырдым. Тик алай да күнегүләр ясаудан туктамадым, терелүгә үк Украина кубогына ярышта катнашып, 218 сантиметр биеклекне сикереп, җиңү яуладым. Бу 1979 елда, минем соңгы тапкыр ярышуым булды. Алга таба нишләргә дигән уй килде. Байтак еллар буе туплаган тәҗрибәне болай гына ташлыйсым килмәде. Фән белән дә шөгыльләнергә, бер үк вакытта китап та язып карарга дигән карарга килдем.

— Нинди китап? Мемуарлармы?

— Сез минем тарихны беләторгансыздыр бит? Аны «Рөстәм Әхмәтов феномены» дип инде байтактан сөйлиләр. Асылы, моннан гыйбарәт: минем әтием Фәһим Абдрахман улы хәрби кеше иде. Сугыштан соң аларның артиллерия часте Украинадагы Бердичев дигән калада төпләнә. Шунда 1947 елда апам Ираида, 1950 дә мин туганмын. Менә шул калада Виктор Лонской дигән кеше биеклеккә сикерүчеләр мәктәбе оештырып җибәрә. Шәһәр артык зур булмагангамы, әллә бала-чаганы кызыктырырлык башка шөгыль булмагангамы, без малайлар көтүебез белән шуңа йөрдек. Ул чакта миңа унике яшь иде. Тиздән Украина, аннан илнең яшьләр командаларына керерлек спортчылар үсеп җитте. Өч-дүрт ел эчендә мин дә беренче разряд нормасын үтәдем. Ләкин шуннан соң күрсәткечләрем үсүдән тукталды. Иптәшләрем һаман саен биеккәрәк сикерә, ә мин бер урында таптанам. «Нигә алай?» — дип тренерыбыздан сорыйм. Ә ул көлә генә. «Рөстәм, синең буең кечкенә. Син инде үзеңә тиешле биеклекне күптән сикереп чыктың. Тагын да биегрәк сикерү өчен сиңа үсәргә кирәк», — ди. «Ә ничек үсәргә соң?» — дип сорыйм. Виктор Алексеевич болай ди: «Бер бит кәгазь, каләм ал да яз. «Мин Рөстәм Фәһим улы бер ел эчендә сигез сантиметрга үсәргә йөкләмә алам», — диген».

Шулай иттем дә. Яздым да, бу кәгазьне иң күренеп торган җиргә элеп куйдым. Ә үзем уйлыйм. Безнең нәселдә озын буйлылар юк. Әти дә, әни дә буйга 165 сантиметрлар тирәсе генә. Үсәсем килә дип кенә табигать биргәнне үзгәртеп булырмы икән? Шулай да үсәргә ныклап алынырга булдым. Шул көннән башлап үсәсе килү, үсәргә тырышу минем тормышымның мәгънәсенә әйләнде. Китаплардан, журналлардан үсәргә булыша торган күнегүләр эзләдем. Халык арасында йөргән әкиятләрне, риваятьләрне өйрәндем. Үзем генә түгел, өйдәгеләрнең барысы да мине үстерү җаен эзләделәр. Озаклап турникта эленеп торулар да, йокларга ятканда гәүдәне тартып тора торган резин тасмалар бәйләп яту да, кәнәнә йөзәр-меңәр тапкыр түшәмне тотам дип сикерүләр дә — берсе дә калмады. Әнием, витаминга бай дип, капчык-капчык кишер ташыды. Ул каяндыр үстерә торган күнегү ясау алымын да өйрәнеп кайтты. «Безнең халыкта шундый бер риваять йөри иде, — дип сөйли иде ул. — Тизрәк җитешсен дип, аналар улларын сузып яткырганнар да, аларның күкрәгендәге нервлары оешкан урынны сыпырып, «Үс, улым, үс!» дип сыйпый торган булганнар. Ул мине «Үс, улым, үс!» дип сыйпаганда миңа, чынлап та, гәүдәм үзеннән-үзе сузылып киткәндәй була торган иде.

Җәен авылга, әбиләр янына кунакка кайткач, мин тагын бер үстерү алымына тап булдым. Әбиләр, апалар токмачны куна тактасында уклау белән тәгәрәтеп ясыйлар иде. Карап торам — калын камыр кисәге уклау белән куна арасына кереп кысылгач, тәгәрәтүдән һаман саен юкара һәм озыная бара. Шуңа охшашлы алымны мин дә күнегүләрдә файдаланып карарга булдым. Тау башына менәм дә, тәгәрәп төшәм. Гәүдәм, бик тиз бәтерелгәндә, үзәктән куу көче законына буйсынып, уклау белән куна арасында калган камыр кебек, озынаерга тиеш кебек тоела.

Бер елдан соң үлчәнеп карасам, менә могҗиза... чынлап та, сигез сантиметрга үскәнмен. Тренерым моны белгәч «Менә мин сиңа әйткән идем бит», — дип көлде. Икенче елда да шундый ук тырышлык белән тагын шулкадәр үк үстем. Тренерым шуннан соң. «Өченче елда биш кенә сантиметрга үсәргә кирәк, югыйсә гәүдәңне тотып тора алмассың» — диде. Ул елда биш кенә сантиметрга үстем. Шулай итеп, мин өч ел эчендә үз теләгем белән 21 сантиметрга үсеп, 187 гә җиттем. Бер үк вакытта биеккәрәк тә сикерә бардым, шәхси рекордымны 223 сантиметр җиткердем.

Бу хакта башкаларга да билгеле булгач, минем белән ныклап кызыксына башладылар. «Рөстәм Әхмәтов феномены» дигән атама әнә шулай туды. Ябышты миңа хатлар яварга. Баштарак аларның һәрберсенә җавап язарга тырышсам да, алар көннән-көн күбәя барды. Мин аларның Татарстаннан һәм чит илләрдән килгәннәренә генә җавап язарга өлгердем. Үземдәге тәҗрибәне башкалар белән дә уртаклашасы килү миндә китап язу теләген кабызды. Аны быел Житомирда 10 мең тираж белән чыгардылар. Буйга үсәсе килгән кеше аннан бик күп файдалы киңәшләр ала ала.

— Бу китапны бездә дә чыгарып булмыймы соң?

— Мин үзем дә шул хакта уйланам. Үзебезнең халык туган телендә укысын, файдалансын. Татарстанның Матбугат һәм информация министрлыгында очрашу вакытында да шул хакта сөйләшеп алдык. Бергәләп алынсак, бәлки, артык озакка сузмыйча халыкка җиткереп булыр иде.

Әңгәмәдәш — И.ИЛДАРХАНОВ.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ

ҖОМГА, 26 ФЕВРАЛЬ «ТАТАРСТАН» КАНАЛЫ

7.00-8.00 «Чулпан».
18.05 Фазыл бабай әкиятләре. «Төш юраучы малай».
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.30 Реклама курьеры.
19.35 Видеоспорт.
19.45 «Эш эзлим». Мәгълүмат хәбәрчесе.
20.00 Әлли-бәлли-бәү.
20.10 Эфирда — «Адым» студиясе.
20.40 «Җомга көн кич белән» альманахы.

«ОСТАНКИНО» КАНАЛЫ

6.00, 9.00, 12.00, 15.00 — Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантияли.
9.20 Күңелле ноталар.
9.35 Нәфис фильм: «Райский сад».
11.00 Сәяхәтчеләр клубы.
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 Нәфис фильм: «Генеральная репетиция». 1 нче һәм 2 нче серияләр.
14.30 Кыска метражлы телефильм: «Первый поцелуй».
15.25 Бридж.
15.50 Бизнес-класс.
16.05 Куен дәфтәре.
16.10 Нәфис фильм: «Райский сад».
17.30 Алтын табыла торган урын.
17.50 Эш.
18.00 Яңалыклар.
18.25 Алтын урталык.
18.45 Кеше һәм закон.
19.15 «03 нче вагон».
19.45 Могҗизалар кыры.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21 40 Атна кичәсе.
21.55 «Китаец» сериалыннан фильм: «Черный свет» (Франция).
23.30 Политбюро.
0.00 Яңалыклар.
0.20 Музыка күзәтүе.
1.00 Күзәтү мәйданы.
2.00 Пресс-экспресс.
2 10 Футбол. Уэмбли юлында.

«РОССИЯ» КАНАЛЫ

8.00 Хәбәрләр.
8.25 Эшлекле кешеләр вакыты.
8.55 Сәяси Олимпта.
9.50 ТВ-ателье.
10.05 С.Рахманинов. «Литургия».
11 05 Хайваннар дөньясында.
12 05 «Санта-Барбара». 137 нче серия.
12.55 Репортер.
13 10 Ретро-шлягер.
13 40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00 Хәбәрләр.
14 25 Ижица.
14 55 Чаңгы буенча дөнья чемпионаты. 4х10 километрга эстафета. Ирләр.
16 30 Телебиржа.
17 15 Манара.
17 30 Җәй кышлаган җирдә.
18.00 Дисней мультипликациясенең гүзәл мизгелләре.
18.50 М.Цветаева. «Между любовью и любовью распят мой век».
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.25 Кинокомедия: «Его девушка — пятница».
22.05 Халык фрагы.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Йолдызлар сөйли.
23.25 Спорт каруселе.
23.30 Әйдәгез, аңлашыйк.
23.40 Россия Федерациясе Югары Советы сессиясендә.
0.10 Зураб Соткилава күрсәтә.
1.10 Сафсата.

САНКТ-ПЕТЕРБУРГ КҮРСӘТӘ

7.30 Исәнмесез! 7.40, 18.05 Мультфильмнар. 8.00 Киносалон. 9.15, 16.10 Поп-кибет. 9.25 Телефильм: «Моя вторая мама». 10.15 «Кара көш артыннан». 10.30 Си-эн-эн. 11.05 Нәфис фильм: «Дневной поезд». 12.45 Альтернатива. 13.45 Нәфис фильм: «Перед судом истории». 15.30, 20.20 Факт. 15.40 Фильм концерт. 16.45 Нәфис фильм: «Стальное колечко». 17 15 Уртак йортыбыз. 17.45 Би-би-си. 18.30 «Послание к человеку» фестиваленең кайтавазы. 19.00 Зур фестиваль. 19.15 Музыка белән күзгә-күз. 20.00 Документаль фильм. 20.45 Спорт, спорт, спорт. 21.00 Музыкаль яңалыклар. 21.35 600 секунд. 21.50 Сезнең стиль. 21.55 Акцент. 22.10 Камертон. 23.10 Телеафиша. 23.30 Голливуд йолдызларының Рождество парады. 1.05 Нәфис фильм: «Две дуэли». 1 нче һәм 2 нче серияләр.

«ЭФИР» КАНАЛЫ

9.50 Телетекст.
10.00 «Супер-чэннел» программасы.
17.05 Мультфильмнар.
18.00 Нәфис фильм: «Свадьба Си્ти» (Һиндстан).
19.45 «Шәһәр» информацион программасы.
20.05 Бөтендөнья яңалыкларыннан дайджест.
20.15 Видеоклиплар.
20.25 Нәфис фильм: «Смит по прозвищу «Ураган» (боевик).
21.50 «600 секунд».

Баш редактор Ренат ХАРИС
Телефоны: 32-41-79
Газетаның индексы 54129

Безнең телефоннар:
кабул итү бүлмәсе — 32-41-79; баш редактор урынбасарлары — 32-45-78, 32-06-76, 32-25-58; җаваплы секретарь — 32-57-36; секретариат 32-57-76; сәясәт редакциясе — 32-12-08, 32-59-55; экономика редакциясе — 32-68-22, 32-27-42; информация редакциясе — 32-30-49, 32-58-89, хатлар һәм оештыру редакциясе — 32-59-55, 32-69-54, 32-57-76; тәрбия бүлеге — 32-57-48; әдәбият-сәнгать бүлеге — 32-59-22; тәрҗемә бүлеге — 32-63-96; фотохәбәрче — 32-69-26; корректорлар — 32-57-07; стенографист — 32-69-54; компьютерлар залы — 32-57-07; бухгалтерия — 32-57-94. Үз хәбәрчеләребез: Азнакайда — 9-24-23, Баулыда — 2-15-29, Лениногорскида — 2-46-70, Мамадышта — 2-14-94, Түбән Камада — 4-19-37.

ГАЗЕТАНЫҢ ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ — ТАТАРСТАН ЮГАРЫ СОВЕТЫ ҺӘМ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ.

Газета БДБ илләре каталогына кертелгән. Атнага биш тапкыр чыга, аңа ел дәвамында язылырга мөмкин.
Редакциянең фикере авторлар фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Килгән хатлар, кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Газета компьютерда эшләнә.

Адресыбыз: 420111, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19.
Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясендә басылды.
Тираж — 21.000
Газета басылуга кул кую графигы буенча 20 сәгатьтә. Бу санга 19 сәгатьтә кул куелды.
Заказ 2246

«Татарстан хәбәрләре»н АКШ Конгрессы, Төркиянең Милли,Нью-Йорктагы җәмәгать китапханәләренә, Төрки халыклар тарихын өйрәнү институтына (Истанбул) алдыралар.